# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИЖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

4/ 2025

**Милли кием ул музей экспонаты гына түгел, ә безнең көннәрдә икенче сулышын алган җанлы, үсә баручы организм**









# Балалар паркында – «Уен Фест. Аҗаган» V Регионара фестиваль-конкурс

**Быелның 7 сентябрендә «Елмай» балалар паркы меңнәрчә гаиләне бергә җыйды. Биредә «Уен Фест. Аҗаган» V Регионара фестиваль-конкурсның финалы узды. 3 500дән артык тамашачы һәм чарада катнашучылар борынгы татар һәм рус халык уеннары, иҗат һәм спорт дөньясына чумды.**

Кунаклар өчен бик бай программа әзерләнгән иде:

– аниматорлары да булган уен зоналары;

– Казан театрлары актерлары һәм әкият геройлары җитәкчелегендә уздырылган борынгы халык уеннары;

– корама тегү, тукучылык һәм агачка бизәк төшерү буенча иҗади мастер-класслар;

– Татарстанның иң яхшы балалар коллективлары чыгышлары;

– «Уен Фест. Аҗаган»ның спорт ярышлары һәм команда конкурслары;

– спектакль кую, кинофильм күрсәтү һәм өстәл уеннары өчен уңайлы зона.

Конкурс программасының финалы бәйрәмнең кульминациясе булды, анда иң көчле 7 команда «иң яхшылар» исеме алу өчен көч сынашты. Теләче районының «Чулпан» командасы җиңү яулады һәм фестивальнең Гран-приена ия булды. Җиңүчеләрне күркәм приз – Мәскәүдәге «Хыял утравы» паркына бару көтә.

Шулай ук:

– Биектау районы Шәпше авылы Мәдәният йортының «Фирүзә» командасы – I дәрәҗәдәге лауреат;

– Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылы Мәдәният йортының «Балкыш» командасы – II дәрәҗәдәге лауреат;

– Яшел Үзән районы «Ал җилкәннәр» Балалар мәдәният йортының «АлПар» командасы – III дәрәҗәдәге лауреат булдылар.








**Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан**

# Эчтәлек


**ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ**



4 **Петербургтагы XIV халыкара газ форумында Татарстан стенды**

6 **Ульяновскида татар милли киеме курслары**

9 **Яшь фольклорчы мәктәбендә катнашучылар Идел буе халыкларының фольклор мирасы турында фикер алыша**

**ТАТАР МОХИТЕ**



12 Д. Сәләйманова
**Гадәти татар өе**

**ӘДӘБИ МИРАС**



22 Л. Мөхәммәтҗанова
**Зәй районында татар фольклоры: үткәне һәм бүгенгесе**



**Түгәрәк уен**
№ 4 (58) / 2025


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

**Гамәлгә куючылар:**
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге



**Редколлегия:**
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

**Директор:**
Алсу Равил кызы Мифтахова
**Баш мөхәррир:**
Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

**Альманахның иҗат төркеме:**
Гөлназ Латыйпова
Илнара Гәрәева

**Дизайнер һәм биткә салучы**:
Диләрә Нәүрузова



Альманах 2020 елның 13 ноябрендә Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә (Роскомнадзор) ПИ № ФС77-7959090 номеры белән теркәлгән.
Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 11.12.2025
Чыгу көне: 26.12.2025
Заказ: № 396. Тираж: 1000 экз.

**Редакция һәм нәшер итүче:**
420021, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан, Тукай ур., 74 а.
**Хатлар язар өчен адрес:**
420015, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан, Пушкин ур., 66/33, тел.: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

Отпечатано в ИП Селиванова А.Г.
420015, Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Галактионова, 14
тел.: +7(843)2382449
E-mail: Orange_k@list.ru



Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.


**Тышлыкта:** «Ел һөнәрчесе-2025» Республика конкурсы җиңүчесе Айгөл Фәйзрахманованың кулдан эшләнгән «Бибинур һәм Җиһангир» баш киемнәре комплекты фрагменты


© «Түгәрәк уен», 2025

ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...



30 Р. Исмәгыйлева
**Полиция капитаныннан – сәнгать остасына**

МИФОЛОГИК МИРАС



34 Г. Гыйльманов
**Теләк теле беләсезме?**

БЕЗГӘ ЯЗАЛАР




38 Д. Таҗиев
**Әлифба рухи азыгыбызның башлангычы**

42 Р. Галләм
**Нәсел тамгалары – халкыбызның уникаль тарихи мирасы**

БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ




49 **Яшәү белән үлем**

БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...



52 Л. Мөхәммәтгалиева
**Милли хәзинәләр – буыннарга мирас**

56 Г. Зәйнакова, Р. Гарифуллина, А. Гаффарова
**Алтын алмалар**

59 **Чыланган чыршылар** *(җыр)*

ӨЙ КҮРКЕ – АШ



60 **Уалма**

ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

62 **Бергәләп бизибез!**




# Петербургтагы XIV халыкара газ форумында Татарстан стенды

2025 елның 7-10 октябрендә Санкт-Петербургта XIV халыкара газ форумы булып узды. Форум эшендә безнең республика да катнашты. Татарстан стенды, иң күренеклеләрнең берсе булып, форум кунакларына һәм анда катнашучыларга борынгы традицияләр, сәнгатьнең көче һәм җанлы мәдәни тормышның уникаль бердәмлеген тәкъдим итте.

Безнең экспозиция татар мәдәни кодының дүрт төп концептын үз эченә алган иде: «Бәрәкәт», «Хәрәкәт», «Белем» һәм «Нәсел».

«Бәрәкәт» зонасында сәнгатьчә ювелир эшләнмәләр, шул исәптән күренекле рәссам-реставратор Рәфкать Мөхәмmәтшинның Болгар һәм Алтын Урда чоры бизәкләре реконструкцияләре, шулай ук укалап чигү осталарының эшләре тәкъдим ителде.

«Хәрәкәт» бүлеге Татарстанның сәнәгать көчен күрсәтте. Үзенең 50 еллык юбилеен билгеләп үтәргә хәзерләнүче «КамАЗ» АҖП, шулай ук Казан вертолет заводының авиация техникасы һәм Яшел Үзәндәге А.М. Горький исемендәге заводның инновацион суднолары (сыегайтылган табигый газда






эшләүче «Чайка» судносын да кертеп) макетлары игътибар үзәгендә булды.

«Белем»нең нигезендә мәгариф һәм фән традицияләре иде. Кунаклар Татарстан Республикасы Милли китапханәсе фондының сирәк кульязмалары һәм борынгы китаплары, шулай ук бөек галимнәр Николай Лобачевскийга һәм Арбузовларның химиклар династиясенә багышланган экспонатлар белән таныштылар.

«Нәсел» концепциясе бөек шагыйрь Габдулла Тукай шәҗәрәсе һәм Казан сәнгать училищесы студентларының дөньяда тиңе булмаган уникаль һөнәр – татарларның күн мозаикасы техникасында башкарылган хәзерге заман эшләнмәләре аша ачылган иде.

Татарстан стенды кунакларга карау мөмкинлеге генә түгел, мәдәният белән турыдан-туры очрашу мөмкинлеге дә тудырды. Форум көннәрендә биредә түбәндәге традицион һөнәрләр буенча мастер-класслар уздырылды:

– уникаль «Казан җөе»н өйрәнү буенча күн мозаикасы;

– күләмле чәчәк композициясе тудыру өчен элмәкле аппликация;

– киез басу;

– челтәр үрү;

– «Эбру» техникасы белән суда рәсем ясау.

Халык уеннарын торгызуга юнәлдерелгән «Уен Фест» проектын презентацияләү дә зур вакыйга булды. Аның мәйданчыгы төрле яшьтәге кунакларны үзенә җәлеп итте, алар милли татар уеннарына дәртләнеп кушылдылар, биеделәр һәм «Милли лото»да катнаштылар.

Иҗаты борынгы уен кораллары аһәңенә нигезләнгән «Кадим Әлмәт» этно-коллективы чыгышлары мондагы атмосфераның аерылгысыз өлеше булды.





# Ульяновскида татар милли киеме курслары



Бу елның октябрь азагында Ульяновск шәһәре ике көн дәвамында татар мирасын хөрмәт итүчеләр өчен чын мәдәни башкала булды. Биредә «Татар милли киеменең тарихы һәм бүгенгесе» курслары зур уңыш белән барды, ул иҗат коллективлары җитәкчеләреннән һәм фольклор ансамбльләре артистларыннан алып, йөрәкләрендә татар традицияләренә һәм сәнгатенә карата мәхәббәт яшәгән энтузиастларга кадәр бик күп катнашучыларны үзенә җыйды. Курслар Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге тарафыннан оештырылды.

Курсларның программасы гаҗәеп дәрәҗәдә бай һәм күпкырлы иде. Белем арттыручы чаралардан тыш, курсларда катнашучылар «Татар милли киеменең тарихы һәм бүгенгесе» күргәзмәсе белән таныштылар, анда XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында шәһәрдә яшәгән төрле буын татар



гаиләләре киемнәренең чын үрнәкләре тәкъдим ителде. Алар Татарстан Республикасы Милли музее фондындагы предметлар (баш киемнәре, эчке һәм тышкы киемнәр, аяк киемнәре, бизәнү әйберләре) нигезендә булдырылганнар. Әлеге күргәзмәгә балалар – Ульяновск мәктәпләре укучылары да килгән иде.

Әйдәүче экспертларның чыгышлары чараның интеллектуаль үзәге булды. Сәнгать белеме докторы Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова (бу өлкәдә аның тикшеренүләре эталон булып тора) «Татарларның милли киемендә традицияләр һәм хәзерге заман» дигән тирән эчтәлекле доклад ясады. Ә дизайнер һәм BURO BANU брендына нигез салучы Элара Шәйхи, традицион



киемнәрнең актуаль fashion үрнәкләр тудыруга илһамландыруы турында сөйләде.

Курсларда мастер-класслар да уздырылды. Рәссам-каллиграф, Баки Урманче исемендәге премия лауреаты Гөлназ Исмәгыйлева уздырган «Татар шамаиле техникасы» дәресендә курста катнашучылар борынгы сәнгать белән таныштылар.

Курсларның гамәли юнәлеше аеруча зур әһәмияткә ия иде. Эшлекле һәм профессиональ элемтәләр булдыру буенча җанлы дискуссияләр үткәрү кысаларында коллектив җитәкчеләре һәм педагоглар бәяләп бетергесез тәҗрибәләре белән уртаклашып кына калмадылар, ансамбльләренә заманча детальләр өстәп, аларны баету өчен яңа образлар да таба алдылар.



Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылының «Мишәрләр» фольклор-этнографик балалар ансамбле эшен күрсәтү – традицияләрнең яшәвен һәм яшь буынга тапшырыла баруын раслаучы ачык дәрес иде.

Ульяновскидагы әлеге ике көн татар мәдәниятен саклау һәм үстерү белән кызыксынучы һәркем өчен чын бәйрәм булды. Ул милли киемнең музей экспонаты гына түгел, ә безнең көннәрдә икенче сулышын алган җанлы, үсә баручы организм булуын раслады.



# Яшь фольклорчы мәктәбендә катнашучылар Идел буе халыкларының фольклор мирасы турында фикер алыша





Быелның 24 ноябрендә Алабуга мәдәният һәм сәнгать колледжы бик зур белем бирү чарасы – Яшь фольклорчы мәктәбенең Республика семинар-практикумы мәйданына әйләнде. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге тарафыннан оештырылган әлеге проект өч күренекле датага: Ватанны саклаучылар елына, Бөек Ватан сугышының 80 еллыгына һәм В.Д. Поленов исемендәге Россия Дәүләт Халык иҗаты йортының 110 еллыгына багышланган иде.







Әлеге чара бөтен республиканың этнологларын, сәнгать белгечләрен, практикларны һәм иҗат коллективларын җыйды. Яшь фольклорчы мәктәбенең төп максаты Идел буе халыкларының гаҗәеп бай фольклор мирасын саклау, өйрәнү һәм актуальләштерү иде. Тарихи истәлекләрне өйрәнүгә заманча якын килү һәм патриотизм тәрбияләү өчен аның фольклорда һәм традицион мәдәниятта чагылышы фикер алышуларның үзәгендә торды.

Семинар-практикум программасы бик бай һәм күптөрле иде. «Алабуга» һәм «Кама таңнары» халык ансамбльләре башкаруындагы «Сабантуй» композициясе белән башланып киткән тантаналы ачылыштан соң, семинарда катнашучылар «Татар халкының традицион киеме», «Этнофото» һәм «Татарстан Республикасының



чигелгән картасы» дигән тематик күргәзмәләр белән таныштылар.

Пленар утырышта Казан федераль университеты һәм Казан дәүләт мәдәният институтының этнография өлкәсендә әйдәп баручы белгечләре XXI гасыр традицияләрен өйрәнүдәге актуаль мәсьәләләр, халык календаре һәм сугыш тематикасында татар бәетләре турында фикер алыштылар.

Семинар эше специальләшкән дүрт секциядә дәвам итте, анда катнашучылар традицион мәдәниятнең төрле аспектларын практик яктан өйрәнү белән шөгыльләнде.

Семинар азагында фольклор-этнографик «Марфа Иванова» спектаклен карау һәм фикер алышу зур эмоциональ күтәренкелек тудырды. Спектакльне Липецк шәһәре халык иҗатының «Воскресение» фольклор ансамбле коллективы тәкъдим итте. Биредә борынгы җырларга нигезләнеп, тормышы һәм уникаль җырлау сәләте Россиянең иң мөһим тарихи вакыйгалары белән үрелгән гади крестьян хатынының язмышы турында сөйләнә. пектакль фольклорда гәүдәләндерелгән халык хәтере көченең ни дәрәҗәдә зур булуын чагылдырды.



**Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан**

# ГАДӘТИ ТАТАР ӨЕ

**Диляра Сөләйманова,**
*тарих фәннәре кандидаты*



**Гасырлар дәвамында Урта Идел буе һәм Урал төбәкләрендә яшәгән татар крестьяннарының торак йортлары нигездә такта өйалдына тоташкан дүрт почмаклы агач йорт булган. Мондый йортларның эчке күренеше элек-электән килгән үрнәккә буйсынган, ул шәхси зәвыкларга һәм өстенлекләргә урын калдырмаган диярлек. Бер яктан, традицион интерьерга аның этник үзенчәлеген билгеләүче тотрыклы, аз үзгәрүчән компонентлар хас булса, икенче яктан, ул яңа социаль-икътисади шартлар йогынтысында үзгәрмичә дә кала алмаган.**



**Карл Гун. Бердибәк Чаллысы авылындагы мулла йортының эчке ягы. Акварель. 1862 ел. Дәүләт Рус музее**

Традицион торакның эчке төзелеше һәм функциональ бүленеше нигездә өйдәге иң зур һәм әһәмиятле объект – икмәк пешерә торган мичкә карап гамәлгә ашырылган. Аның урыны һәм мич авызының кайсы якка каравы функциональ зоналар (азык әзерләү, хуҗалык эшләре өчен – кухня һәм гаилә белән күмәкләп утыру, кунаклар кабул итү өчен – түр) белән билгеләнгән. Өйнең кухня өлеше эчке, шәхси аралык булып саналган, аны чит күзләрдән яшерергә тырышканнар, ә кунак кабул итә торган өлеше һәркемгә ачык тышкы тирәлек



**Татар сәүдәгәре өендә. Билгесез рәссам. Киндергә майлы буяулар белән ясалган рәсем. XIX гасырның беренче яртысы. Татарстан Республикасының Милли музее**

булган. Эчке тирәлек – хатын-кызларныкы, тышкысы ир-атларныкы булып саналган. Алар арасындагы бәйләнеш төрле халыкларның гадәти тәҗрибәләре белән расланган[1].

Традицион татар өенең эчке төзелешенә түбәндәгеләр хас булган.

Мич, гадәттә, ишектән кергәч тә уң якта, түргә якынрак урнаштырылган. Аның авызы алгы як стенага-диварга карап торган. Кулдан тукылган чаршау яисә XIX гасыр урталарында барлыкка килгән, түшәмгә кадәр җиткерелмәгән агач бүлмә (такта стена-дивар) өй эчен төрле зурлыктагы ике яртыга бүлгән: ирләр ягы – түр як һәм хатын-кызлар ягы – почмак як. Мондый бүленеш мөселман мәдәнияты традицияләренә туры килә: ир һәм хатын-кыз асылы бербөтеннең аерым өлешләре булып саналган, һәм алар төрле функция башкарганнар.



**Икмәк пешерү миче. Татар авылы. Ачык һавадагы этнографик музей**

[1] Байбурин А.К. Жилище в обрядах и представлениях восточных славян. – Л., 1983. – С. 78.

Татарларның икмәк пешерә торган мичендәге үзенчәлек, аның кырыена кертеп урнаштырылган һәм өстенә казан утыртылган учагы булган. Милли ашамлыклар шул казанда хәзерләнгән. Рус һәм фин-угор халыкларына хас мич башы (йоклау урыны) татарларда булмаган, мичнең түр якка карап торган стена-диварына уентылар, кәрнизләр ясалган, кабарынкы бизәкләр төшерелгән.

Мичле өй генә торак йорт булып саналган. Татар халкында шундый мәкаль дә бар: «Мичсез өй – мисез баш». Мич гаилә һәм нәсел дәвамчысы булып исәпләнгән, изге урын буларак сакланган. Борынгы йолаларның берсе буенча, кияве йортына аяк баскач, кәләш мичне үбә яисә аңа иреннәрен тидерә, шул рәвешчә әлеге нәселнеке булып исәпләнә башлый[2]. Халык аңында мич кеше белән тәңгәлләштерелә, аны «ак» хатын-кыз яисә әби итеп күзаллыйлар, бу хатын-кызның гаилә учагына бәйлелеге турында сөйли. Янган учактагы ут һәм мичнең тоташуы – бу ир һәм хатын-кыз башлангычларының тоташуы, нәсел дәвамчанлыгы күренеше. Күп кенә халыкларда символик рәвештә торгызылган учак турыдан-туры гаилә иминлеге белән тәңгәлләшә. Төркиләрнең күчмә тормышы традициясе буенча нәсел символлары булган ут һәм учакны гаилә әгъзалары сүнүдән саклаган. Учакның сүнүе йортка бәхетсезлек алып килүче начар билге булып саналган.

Йортның бөтен алгы стенасы-дивары буенча киң агач сәке урнаштырганнар. Ул торакның шактый зур өлешен алып торган – биеклеге 50-60 см, ә киңлеге 1-2 метр булган. Сәке өй эчендәге күп функцияле элемент булып саналган. Гаилә әгъзалары күпчелек вакытларын шунда үткәргән – ашаганнар, эшләгәннәр, кунаклар кабул иткәннәр, йоклаганнар. Төрле җиһазлар –



**Авыл йортының кунак бүлмәсе интерьеры. Көнбатыш Кама аръягы. Этнограф Н.И. Воробьев фоторәсеме. 1926 ел**

[2] Мухамедова Р. Г. Татары-мишари: историко-этнографическое исследование. – М., 1972. – С. 43.



Авыл йорты интерьерының бер кисәге. Арча районы. Реконструкция. 1980нче еллар



**Авыл йорты интерьерының бер кисәге. Олы Ачасыр авылындагы К. Насыйри музей-йорты. 2000нче еллар**

сандыклар, тәңгәлләр (уку һәм язу өчен кечкенә өстәлләр), урын-җир кирәк-яраклары да сәке өстенә урнаштырылган. Ул эчке архитектураның бер элементы – идәннең «күтәренке» өлеше булган, татарларга хас утыру рәвеше – идәндәге кебек сәкедә аякларны бөкләп утыру да шул хакта сөйли. Сәке, мич кебек үк, өйнең зур объекты булып саналган, көнкүрештәге башка җиһазларны аңа карап урнаштырганнар.

XVIII-XIX гасырның беренче яртысында татар йортында, күп кулланылучы сәкедән, сандыклардан һәм киштәләрдән файдаланганнар. Стена-дивар буйлап урнаштырылган берничә сандык әйберләр саклау өчен генә түгел, җиһаз булып та хезмәт иткән. Алар өстенә урын-җир кирәк-яракларын өеп куйганнар, анда утырганнар, балаларны йоклатканнар. Түшәм астында, арткы, алгы һәм ян стена-диварлар буйлап, агач шүрлекләр яисә бер яки ике параллель рәвештәге колга-киштәләр урнаштырганнар. Анда көнкүреш әйберләрен, урын-җир кирәк-ярак-ларын, китаплар куйганнар, тукыма бизәкләр элгәннәр.

XIX гасырның икенче яртысыннан башлап, традицион татар интерьерында үзгәрешләр күренә башлый. Шәһәр белән авыл арасында элемтәләр арту белән, анда шәһәр тормышына хас булган җиһазлар, предметлар урын ала.

Авыл йорты интерьерына шәһәрдән күчкән җиһазлар түбәндәге принцип буенча үтеп кергән: беренче чиратта, алар көндәлек тормышта кирәк булган өчен түгел, ә гаиләнең иминлеген, муллыгын күрсәтү өчен урын алган. Мәсәлән, сәгатьләр, көзгеләр, пыяла ишекле буфетлар, фарфор савыт-саба шундыйлардан булган.

Шәһәр йогынтысы астында авыл татарлары йортында чәй өстәлләре һәм урындыклар



Авыл йорты интерьерының бер кисәге. Олы Ачасыр авылындагы К. Насыйри музей-йорты. 2000нче еллар

пәйда булган*. Аларны өйнең түр ягына, гадәттә ике тәрәзә арасына урнаштырганнар. Татарлар көнкүрешендә ашау һәм кунаклар кабул итү сәкедә яисә идәндә башкарылган. Шуңа күрә өстәлне матур савыт-саба һәм самовар утыртып кую өчен генә файдаланганнар. Чигелгән эскәтер ябылган, бизәкле тастымаллар куелган һәм өстәл түр бүлмәнең өстәмә декоратив элементы булып хезмәт иткән. Урындыклар өстәл артында түгел, ә сәке артында утыру өчен файдаланылган.

Бу чорда савыт-саба кую өчен буфетлар һәм шкафлар аеруча популярлык казанган. Россиянең бөтен Европа өлешенә хас булган стандарт үрнәктәге буфетлар йорт җиһазлары ясау остаханәләрендә дә, вак һөнәрчеләр тарафыннан да җитештерелгән. Мондый буфет аскы яктан аз гына алга чыгып торучы, ике якка ачылучы капкачлы ишекләре булган кечкенә агач шкафтан торган; өске өлеше агач, кайберләрендә пыяла ишекләр белән ябылган. Мондый буфетларга матур фарфор савыт-саба һәм вак-төяк әйберләр куела торган булган.

Татар өе интерьерында, бигрәк тә хәлле крестьяннар арасында иң яраткан предмет сәгать исәпләнгән. Ул көндәлек тормышта файдаланудан бигрәк, декоратив максатларда кулланылган. Этнограф Н.П. Штейнфельд әйтүенчә, «…дивар сәгатенә татарлар аеруча игътибарлы. Бай йортта һәр бүлмә һичшиксез сәгать белән бизәлгән була, ә бер кешенең кечкенә генә бүлмәсендә миңа бик зур футлярлар эченә урнаштырылган ике сәгать күрергә туры килде…»[3]

Татарларда сырлап эшләнгән агач кысалардагы көзгеләр дә югары бәяләнгән. Хәлле крестьян өенең түр өлешендә, тәрәзәләр арасындагы диварларга хәтта берничә сәгать эленә торган булган.

Көндәлек тормышта татарлар үзенчәлекле йола булып саналучы чәй эчү гадәтенә аеруча зур игътибар биргән. Хәлле гаиләләрдә чәйне




**Шамаил үрнәге. XX гасыр башы. Татарстан Республикасының Дәүләт сынлы сәнгать музее**

Кытайда яисә Германиядә җитештергән фарфор савытлардан эчкәннәр. Самоварлар бик киң таралган. Бер генә татар гаиләсе дә чәй сервизыннан башка һәм самоварсыз яшәмәгән, аларның сыйфаты муллык дәрәҗәсе билгесе булып хезмәт иткән.

Мөселманнарның табыну әйберләре, шул исәптән өйнең алгы һәм ян диварларына элеңгән шамаилләр, гадәти татар интерьерының аерылгысыз өлеше булып торган. Шамаилләр декоратив бизәк булып кына хезмәт итмәгән, ә йорт хуҗаларының мөселманнарның дини гореф-гадәтләренә бирелгәнлеген дә күрсәткән. Моннан тыш, алар магик функцияне дә башкарган: йортны явыз көчләрдән саклаган. Шуңа күрә шамаилләрне һәрвакыт керү ишегә – тышкы дөнья белән элемтә гамәлгә ашырыла торган «аеруча куркыныч» зона өстенә элгәннәр.

---

* Мишәрләр һәм керәшен татарлары яшәгән авыл өйләрендәге җиһазлар күрше халыклар, бигрәк тә руслар белән тыгыз аралашу нәтиҗәсендә киң таралган.

[3] Штейнфельд Н. П. Малмыжские татары, их быт и современное положение // Календарь и памятная книжка Вятской губернии на 1894 г. – Вятка, 1893. – С. 293.



**Татар авылы өендә кунак бүлмәсе интерьерының бер кисәге. Реконструкция. Яңа Кырлайдагы Г. Тукай музее. 1980нче еллар азагы**

Тәһарәт алу һәм юыну өчен хезмәт итүче бакыр яисә җиз комганнар һәм ләгәннәр татар интерьерының тагын бер үзенчәлекле детальләре булган. Комган һәм аның янәшәсендәге өйдә тукылган сөлге белән җиз ләгән татар өенең этник һәм дини символы булып исәпләнгән. Интерьерның тагын бер шундый ук әһәмиятле детале – гарәп һәм фарсы телләрендә язылган мөселман китаплары, матур итеп бизәлгән кулъязма яки кün тышлы басма Коръәннәр.

Татар өенең декоратив бизәлешендә нәфис һәм утилитар тукымадан ясалган әйберләр, киез һәм келәм эшләнмәләр, урын-җир кирәк-яраклары һәм кием-салым төп рольне уйнаган. Өйнең эчендә күп санлы чаршаулар булган: алар ирләр һәм хатын-кызлар ягын бүлеп торган, керү юлындагы алгы өлешне торакның эчке өлешеннән, сәкегә эленгәннәре йоклау урыннарын бер-берсеннән аерган. Тукыма бизәкләрнең үзенчәлекле төре – «кашага» шул ук «түр буе» – алгы һәм ян диварлар буенча түшәм астына, матча буйлап эленгән, мичнең өске өлешен бизәгән. Алар, түшәм астын каймалап, өстәмә декоратив элемент, үзенчәлекле чаршау булып хезмәт иткәннәр.

Болардан тыш, стеналарны һәм бүлмәләрне бизәү өчен өйдә тукылган һәм чигелгән сөлгеләр, япмалар (эскәтерләр), намазлыклар, тастымаллар файдаланылган. Тукыма эшләнмәләр бер-берсе өстенә берничә данә эленгән, алар агач өйнең диварларын каплаган һәм почмакларны яшергән. Шул ук вакытта тукыманың күплеге һәм катлы-катлы булуы татар интерьерын тирмә бизәлешенә охшаткан. Идәнгә һәм сәкегә киез эшләнмәләр, келәмнәр, мамык көрпәләр һәм мендәрләр урнаштырганда бу охшашлык тагын да көчәйгән – әлеге әйберләр төрки халыкларның тирмәләрендә киң кулланыла торган булган.

Татар интерьерының декоратив бизәлешендә урын-җир кирәк-яраклары әһәмиятле роль уйнаган – төбәкнең төрки булмаган халыкларыннан аермалы буларак, татарларда алар

һәрвакыт күп булган. Матраслар, җәймәләр, мендәрләр, юрганнар сәке яисә сандык өстенә биек итеп өеп куелган һәм чигүле япма белән капланган. Кыйммәтле кием-салым һәм туннар интерьерда үзенчәлекле функцияләр башкарган. Бәйрәм көннәрендә аларны диварларга һәм бүлмә такталарына элеп куйганнар.

Тукыма эшләнмәләр магик саклау көченә һәм символик мәгънәгә ия булган һәм матди җитенкелекне күрсәткән. Мифологик күзлектән караганда, диварларның түшәм белән тоташкан урыннары рухларның югары дөньясы белән кешеләрнең урта дөньясын тоташтыручы урыннар булып исәпләнгән, кашагалар шул куркыныч зоналарны саклаган. Әлеге кашагаларның магик көчкә ия булуы еш кына аларда гарәп шрифтында дини язмалар чигелүдә дә чагыла[4]. Кашага түшәмнең аркылы өрлеге – өйнең тышкы һәм эчке төзелеше арасындагы чик булып хезмәт итүче һәм аерым бер мәгънәгә ия зона булып исәпләнүче матчага да эленгән. Күп кенә халыкларда матчаның «саклау» ысуллары төрлечә булган, русларда, мәсәлән, матчаны шулай ук билгеле бер мәгънәне аңлата торган орнамент белән бизәү кабул ителгән.

Бер-берсе өстенә өеп куелган урын-җир кирәк-яраклары җитешле гаилә символын аңлаткан. Гаилә әгъзалары күбрәк булган саен, әлеге өем дә биегрәк булган, бу исә нәсел агачының дәвамчанлыгын һәм яшәүгә сәләтлелеген күрсәткән.

Яшь парның йокы урынын каплап торучы чыбылдык үз йортларына күченеп киткәнче яңа өйләнешүчеләрнең шәхси тирәлеген бүлеп торган. Чыбылдык татарларның туй йолаларында актив файдаланылган: кайбер районнарда кәләшне ата-анасы йортыннан булачак ире йортына чыбылдык белән капланган махсус туй арбасында күчерү йоласы булган[5].

Тукымадан ясалган бизәү әйберләре нәтиҗәсендә татар өе интерьеры ачык һәм үзенчәлекле колорит, һәм шулай ук чәчәкле-үсемлекле бай орнамент белән аерылып торган. Кызыл, ак, яшел төсмерләр өстенлек иткән. Интерьерның нәфис ансамблендә бүлмә гөлләре – кына, яран, рәйхан әһәмиятле роль уйнаган, алар татар өендә һәрвакыт күп булган. Керү ишегенең капма-каршы ягындагы алгы дивар янындагы урын – өй түре – изге һәм социаль үзәк булып саналган. «Түр» сүзе үзе борынгы төркиләрнең «тормак», «тору» сүзләреннән килеп чыккан, ул «тоткан урын», кабилә, ыруг һәм аерым кешеләрнең үзара мөнәсәбәтен көйләүче канун дигәнне аңлаткан[6]. Көнчыгыш славяннарның «кызыл почмагы»ннан аермалы буларак, төркиләр торагындагы «түр» дини символика белән аерылып тормаган, анда табыну әйберләрен куймаганнар. «Түр» социаль мәгънәгә ия булган. Бу почетлы урынга авылдагы иң абруйлы һәм хөрмәтле кеше – мулланы утыртканнар.

Гаиләнең кече әгъзалары һәм балалар урыны дип кадерсезрәк зона – керү ишеге һәм аның янындагы тирәлек – ишек төбе саналган. Матча ишек төбе һәм өйнең эчке өлеше арасындагы чикне билгеләгән, ул өйнең эчке һәм тышкы өлешләре арасындагы символик чик ролен үтәгән[7].

Татар өенең торак тирәлегендә ике төрле вакытны – кунак кабул итү һәм көндәлек вакытны аерып күрсәтергә мөмкин. Кунак кабул итү вакытында эчке зоналар бары тик гендерлык принцибы һәм социаль иерархия буенча гына бүленгән. Бу бәйрәм табыны вакытында кунакларны утырту йоласында чагылыш тапкан. Табын сәкедәге югары табынга һәм идәндәге түбән табынга бүленгән[8]. Югары табынга кадерлерәк кунакларны – өлкән яшьтәгеләрне, башка авылдан яисә шәһәрдән килгән кешеләрне

[4] Воробьев Н. И. Казанские татары. – Казань, 1953. – С. 193.
[5] Мухамедова Р. Г. Указ. соч. – С. 168.
[6] Толеубаев А. Юрта в представлениях, верованиях и обрядах казахов // Кочевое жилище народов Средней Азии и Казахстана. – М., 2000. – С. 167.
[7] Байбурин А. К. Указ. соч. – С. 145.
[8] Татары Среднего Поволжья и Приуралья / Отв. ред. Н. И. Воробьев, Г. М. Хисамутдинов. – М., 1967. – С. 175.



**Авыл өендә кунак бүлмәсе интерьеры. Яңа Кырлайда Г. Тукайның музей-йорты. 2000нче еллар башы**

утыртканнар. Түр стена уртасындагы түшәкләр һәм мендәрләр өстенә мулла утырган. Аның ике ягына, «почетлылык» дәрәҗәсенә карап, башка кунаклар утырышкан. Кадерсезрәк булып саналган түбән табынга гаиләнең яшьрәк әгъзалары утырган. Йорт хуҗасы үзе дә шунда, ишеккә якынрак җирдә урын алган. Өйнең хатын-кызлар ягындагы табында да шундый ук тәртип булган. Биредә табынны хуҗабикә яисә өлкән килен алып барган, түр башына исә мулла хатынын – абыстайны утыртканнар. Кунакларны утырту, бигрәк тә ике табын белән идарә итү өчен хуҗадан зур осталык һәм әдәплелек таләп ителгән. Байлыгы яисә яше буенча якынча бертөрлерәк, бер-берсенә уңай мөнәсәбәттә булган кешеләрне мөмкин хәтле янәшә утыртырга кирәк булган, юкса аларны рәнҗетү куркынычы туган[9].

Көндәлек вакытта өй эчендәге ирләр һәм хатын-кызлар ягы арасындагы бүленеш алай ук кискен куелмаган. Чит ирләр булмаганда хатын-кыз өй эчендә иркенләп йөргән, һәр ике якта да үз эшләре белән шөгыльләнгән. Гаилә әгъзалары көндәлек вакытта җыелышканда (мәсәлән, табын корганда) почетлы урынга гаилә башлыгы утырган, аның янында, яшь дәрәҗәсенә карап, өлкән уллары урын алган.

Татар өенең эчке төзелеше төрки халыклары тирмәсе төзелешенә охшаш булган. Татарларның традицион торагындагы кебек үк, тирмәдә дә керү ишегенә капма-каршы яктагы махсус почетлы урын аерылып торган[10]. Моннан тыш, охшашлык өй җиһазлары һәм бизәкле тукымалар үзенчәлекләрендә дә чагылыш тапкан. Идәндә табын кору, сәкегә аякларны бөкләп утыру күчмә традицияләр элементларының саклануы турында сөйли. Тирмә белән бәйле кайбер традицияләр хәлле шәһәр татарлары тормышында XIX гасыр азагына кадәр диярлек сакланган, аларда җәй көннәрендә шәһәр читенә пикникларга чыгып, тирмәләрдә яшәү гадәте булган[11].

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**

[9] Там же.
[10] Толеубаев А. Указ. соч. – С. 167.
[11] Воробьев Н. И. Указ. соч. – С. 158.

# Зәй районында татар фольклоры:
## үткәне һәм бүгенгесе

**Лилия Мөхәммәтҗанова,**
*филология фәннәре докторы, доцент,
Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов
исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтының баш фәнни хезмәткәре*

Фольклористика дип аталган фәнни өлкәнең бер тармагы моңа кадәр тупланган халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү белән бәйле зур юнәлеш булса, икенчесе халыктан фольклор үрнәкләрен җыю-туплауга барып тоташа. Татарлар яши торган төрле төбәкләргә махсус чыгып, җирле халыкның рухи һәм матди мирасын барлау, халык белән аралашу нәтиҗәсендә яңа материаллар язып алу, аны фәнни нигездә өйрәнеп, кабат җәмәгатьчелеккә җиткерү – фольклористиканың гына түгел, гомумән, фундаменталь фән белән шөгыльләнә торган академик оешмалар эшчәнлегенең зур бер тармагы. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты татарларның рухи мирасын барлау җәһәтеннән даими эш алып бара. Татарстан районнары, Республикабыздан тыш Россия төбәкләрендә яшәүче милләттәшләребез һәм хәтта чит илдә гомер итүче татарлар да игътибардан читтә калмый. 2025 елның сентябрь аенда оештырылган комплекслы фәнни экспедиция – Институт уздырган әлеге мөһим чараларның иң соңгыларыннан. Экспедициянең зур бурычларының берсен халыкның бүгенге сүз сәнгатен – фольклорын барлау һәм җыйнау тәшкил итә.

### Комплекслы фәнни экспедиция – Зәй районында

Филологиянең һәм сәнгатьнең төрле өлкәләрендә эшләүче, шул исәптән, фольклорчы галимнәр катнашкан комплекслы фәнни экспедиция Татарстанның Зәй муниципаль районында үткәрелде. ТӘһСИның халык иҗаты бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы, ТР ФА профессоры Ләйлә Хәсән кызы Дәүләтшина җитәкчелегендә үткән экспедиция үз эшчәнлеген Зәй районының татарлар тупланып яши торган 17 торак пунктында алып барды. Зәй шәһәре, Аксар, Югары Шепкә, Имәнлебаш, Урта Баграж, Сарсаз Баграж, Югары Налим, Сармашбаш, Дүртмунча, Буракиртә, Югары Пәнәче, Кадер, Түбән Биш, Карман, Куш елга, Бигеш, Сәвәләй авылларында җиде белгеч берничә юнәлештә эшләде.

Фәннең тел үзенчәлекләре, эпиграфик истәлекләр, археографик материаллар, музыкаль традицияләр, халык һөнәрләре һәм сәнгате кебек юнәлешләре белән бергә, Зәй районы фольклор жанрларын өйрәнүгә дә зур урын бирелде, халык иҗаты тарих һәм әхлакый нормаларга бәйле тикшерелде. Шәхсән минем тарафтан, 50дән артык татар телле информант белән турыдан-туры аралашу нәтиҗәсендә,




ТӘһСИдән комплекслы фәнни экспедиция әгъзалары Зәй районында

татар фольклоры юнәлешендә йөздән артык берәмлектә фактик материал тупланды. Алар арасында тарихи һәм тарихи-топонимик, шулай ук генеалогик һәм мифологик риваятьләр һәм истәлекләр, тыюлар, юраулар (төш юрау), мөнәҗәтләр, йола фольклоры текстлары һәм йола фольклоры элементлары, дүрт юллы лирик халык җырлары (кыска җырлар), мәзәкләр, кыйсса-дастан һәм Сак-Сок бәете фабулалары яки аларның эчтәлеген искә төшерү характерындагы истәлекләр, берничә табышмак, мәкаль, имләү текстлы һәм башкалар бар. Экспедициядә катнашкан фәнни хезмәткәрләр авылларда яшәүче информантлар белән актив эш алып барды.

## Фольклорчының төп бурычы – халык белән аралашу

Информантлар – бу районның милли-мәдәни мирасын саклаучылар, аларның сөйләгән тарихлары, җырлаган җырлары, әңгәмә вакытында сөйләмнәрендә чагылып киткән мәкаль-әйтемнәре, шул якка гына хас мәзәкләре, авыллар тарихына багышланган риваятьләре һәм башкалар – бар да безнең өчен кыйммәтле ресурс. Фольклорчы буларак, төп максатым Зәй районының фольклор традицияләрен яңадан өйрәнү һәм заманча контекстта анализлау иде. Экспедиция материалларын беренчел барлап, эшкәртү барышында без халык тарихын, әхлакый нормаларын һәм социаль структураны чагылдырган фольклор жанрларын теркәргә тырыштык, җыелган фольклор материалларын һәм аларның жанр үзенчәлекләрен берничә дистә ел элекке картина белән чагыштырдык, тел-авыз мирасы өлкәсендә чорына хас өстенлекле темалар һәм жанрларны ачыкладык.

Зәй районындагы информантларның күбесе – өлкән яшьтәге кешеләр, аларның хәтерендә халык традицияләре һәм фольклор жанрлары турында күп кенә мәгълүмат саклана. Әңгәмәдәшләрем арасында гомер буе авылда яшәүчеләр дә, чыгышы шул авылдан булып, читтә эшләп, соңгы елларда бирегә күченеп

кайтучылар да бар, яшьләре 42 дән алып 86 яшькә кадәр. Әңгәмәләр барышында халыкның тарихы, гореф-гадәтләре, әхлакый нормалары турында кайбер мәгълүматлар ачыкланды. Алар асылда татар халкы фольклор жанрлары фондын баетулары, моңа кадәр булган традицияләрнең кайсыларының дәвам итүе, кайсыларының әкренләп югалып баруы, кайберләренең исә кабат тергезелүе белән характерлы.

## Зәй – чал тарихлы төбәк

Чулманның сул кушылдыклары булган Чишмә һәм Зәй елгалары арасында XI гасырларда Идел буе Болгарының көнчыгыш чиге уза торган була. Бүгенге Зәй районы урнашкан территория Урта гасырда бөек Ефәк юлының аерымланган бер тармагын тәшкил иткән өстәмә юл өстендә утыра. Казан ханлыгы яулап алынганнан башлап, бу тирәләрне күченү-күчереп утыртылу дулкыны биләп ала. XVII гасыр уртасында (1652-1656 еллар) Чулман аръягында чик буе ныгытмалары төзелә башлый, шуларның берсе – Зәй крепосте. Бирегә иген игүчеләр, шулай ук чик буен саклау өчен рус патшасына тугрылыклы кораллы сугышчылар күчереп утыртыла. Хәзерге Зәй территориясенә караган уңдырышлы җирләр патшага тугрылыклы хезмәткәрләргә – морзаларга бүлеп өләшенә. Бирегә Россиянең үзәгеннән, башка төбәкләреннән крепостной крестьяннарны күчереп утырталар. Зәйгә күчеп килүчеләрнең күбесе казаклар булып исәпләнә, шунлыктан алар күп кенә чикләүләрдән азат ителә. Әлбәттә, моңа кадәр Казан ханлыгы җирләрендә яшәгән җирле татарлар да бирелә яшәп калган. Шул рәвешле XVII гасыр урталары-ахырларында Зәй ягы халкы өр-яңадан формалашу кичерә. Шактый төрле кавемнәрне берләштергән бу урын, 1667 елдан башлап, Зәй шәһәрчеге исемен ала. Бүгенге көндә Зәй районы Татарстан Республикасы составындагы, икътисадының нигезен сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы тәшкил иткән административ-территориаль һәм муниципаль берәмлек буларак яши, милли составы буенча халыкның яртысыннан артыгын татарлар тәшкил итә.





**Л. Мөхәммәтҗанова Зәй районы татар авылларына комплекслы фәнни экспедициядә информантлар белән әңгәмә вакытында. 22-30 сентябрь, 2025 ел**

## Өлкән буын фольклорчылары эзеннән

Зәй районына беренче фольклор экспедициясе 1954 елда оештырылган булган (җитәкчесе – Хәмит Ярми). Ул чордагы фольклор экспедициясе Татарстанның һәм татар халкының фольклор мирасын өйрәнү өчен тарихи әһәмияткә ия. Төбәк территориясендә Х. Мәхмүтов, Х. Курбатов, Ш. Зәбиров, Р. Закирова кебек галимнәр, студентлар язып алган фольклор истәлекләре чын мәгънәсендә алтын бәясенә торырлык. Әйтик, бу экспедиция нәтиҗәсендә тупланган фольклор текстларыннан берничә үрнәк 13 томлык «Татар халык иҗаты»ның «Кыска җырлар» (1976), «Йола һәм уен җырлары» (1980), «Тарихи һәм лирик җырлар» (1988), «Балалар фольклоры» (1993) кебек томнарына урнаштырылган. Ул вакытта җыелган фольклор, халык иҗатының аерым бер жанрларын – җырлар, берничә әкият, такмаза, үртәвеч, тел көрмәкләндергечләрне үз эченә ала. Экспедициядә язып алынган фольклор материаллары тулысы белән Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фондларында саклана.

Зәй районына XX гасыр уртасында узган экспедициядә табылып, академик томнарга кертелгәннәре – бик нык сайлау аша узган сирәк текстлар. Мәсәлән, халкыбызның «Ал итә, итә, итә», «Алым диярсең әле», «Зәй буе» исемнәре белән мәгълүм әйлән-бәйлән, түгәрәк уеннарда җырланган җырлар иң әүвәл нәкъ менә Зәй районы авылларындагы информантлардан язып алынып, фәнни әйләнешкә кертелгәннәр. Зәй районына 1954 елда уздырылган экспедициядә тупланган материалларның күпчелеге халык җырларыннан тора.

Ал итә, итә, итә,
Гөл итә, итә, итә,
Гармунчылар гармунына
Таянып яллар итә.
Үзе су буйларында,
Гармуны кулларында,
Су төбенә карап уйный,
Кем икән уйларында.

Әлеге уен җыры 1954 елда Зәй районы Бигеш авылы яшьләреннән Хуҗиәхмәт Мәхмүтов тарафыннан язып алынып, «Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары» (1980) томына теркәлгән. Әйлән-бәйлән вакытында башкарылган әлеге җыр түгәрәк уртасындагы гармунчыга багышлана. Уен җыры буларак, күңел ачу ихтыяҗы белән башкарыла. Җыр шәхеснең тышкы гүзәллеген, рухи матурлыгын һәм әхлакый сафлыгын чорына хас күтәренке рухта тасвирлап бирә.

Зәйдә үз чорында язып алынган җырларда халык тормышы белән эстетик мөнәсәбәт, тарих чагылыш тапкан. Поэтик камиллек белән бергә җырның иҗтимагый-көнкүреш функциясе дә бик киң. Мәсәлән, 1954 елгы экспедициядә Х. Курбатов Югары Шепкә авылында Халидә Хәйбулла кызы Сәхиевадан (1931 елгы, һөнәре – агроном) язып алган җырны мисалга алыйк:

Җиделе лампа яхшы янмый,
Безгә кирәк унлысы.
Таң алдыннан килеп сайрый
Сандугачның моңлысы.

Махсус фольклор экспедициясеннән тыш, Зәй халкы фольклорга үзе дә бик игътибарлы булган. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фондларын шушы төбәктә яшәгән кешеләрнең үз ихтыярлары белән туплап, Казанга юллаган дәфтәрләренә теркәлгән материаллар да баета. Мәсәлән, XX гасырның 70-80нче елларында Пәнәче авылыннан М. Лукьянов, Сарсаз-Баграҗ авылыннан З. Иванова, Дүртмунчадан И. Смирнова, Кадер авылыннан Ф. Абдуллина, Югары Налимнан Р. Гайфуллина һәм башкалар Институт Мирасханәсенә юллаган материаллар арасыннан берничә үртәвеч, такмаза, тел көрмәкләндергечләр шулай ук академик томнарга кертелгән. Элекке елларда Зәйгә үткәрелгән экспедиция, аннан алып кайтылган материалларның академик томнар өчен сайлап алырлык дәрәҗәдә күп булуы, актив кешеләрнең фондка халык иҗаты үрнәкләрен җыйнап тапшырулары – болар барысы да халкыбызның милли-мәдәни үзбилгеләнүен формалаштыруда мөһим роль уйнаган.

## Хәзерге көн Зәй фольклорының торышы. Җырлар

Зәйдә җыелган җырлар – халыкның көндәлек халәтен, бәйрәмнәрне һәм гореф-гадәтләрне чагылдыручы иң мөһим жанрларның берсе. 1954 елгы экспедициядә җыелган материалларның иң зур күпчелеге кыска һәм уен-бию җырлары булса, бу юлы да Зәй районы татар авылларында, аеруча татарларның керәшен этник төркемендә, татар халык җырларының актив яшәвенә игътибар иттек. Дүртьюллыклардан гыйбарәт кыска җырлар гына түгел, йола җырларының да очравы игътибарны җәлеп итә. Мәсәлән, Имәнлебаш авылының «Җәүһәр» халык фольклор ансамбле (җитәкчесе Э.Г. Әхмәтҗанова) халыкның каен дегете чыгару йоласын сәхнәләштергән. Халык һөнәрен аңлатуга бәйле текстны язып алу барышында информант «Дегет чыгаруны халык бәйрәм итеп уздырган. Җырлары да бар», – дигән мәгълүмат бирде һәм түбәндәге җырны башкарды:

Арба майларга да кирәк
Дегет мае, беләмсең?
Бүген майга юмарт көн бит,
Күп иттереп бирәмсең?
Каенлыкка барган идек,
Дегет мае ясарга.
Дегет ясап, сагыз ясап,
Базарларда сатарга.
Әйе шул, шулай шул,
Базарларда сатарга.

Бу үрнәкне постфольклор дип бәяләгән очракта да, фактик материал буларак, ул шактый кызыклы.

Зәй авылларында быелгы экспедициядә җыелган кыска җырлар, гадәттә, көндәлек тормыш белән бәйле. Аларның эчтәлеге авылда яшәүче кешеләрнең хис-кичерешләрен, сөю-мәхәббәт, туганлык-дуслык, туган як матурлыгы темаларын чагылдыра. Мәсәлән, быелгы экспедициядә Югары Шепкә авылында Гүзәлия Мәгъсүм кызы Вәлиуллинадан (1963 елгы, тумышы белән Зәй районы Аксар авылыннан) язып алынган кыска җырлардан берничә строфасын биредә китереп үтик. 1954 елда җыелган кыска җырлар белән чагыштырып карасак, хәзерге җырларның лирик җырлардагы эмоциональ тирәнлек, традицион образлар, символлар, стиль-композиция үзенчәлекләренең саклануы игътибарга лаек. Информанттан бер дистә берәмлектә язып алынган строфалар заман рухын чагылдыруы белән дә әһәмиятле:

Алларым кая минем лә,
Гөлләрем кая минем?
Унсигез яшемнән сөйгән
Ярларым кая минем?
Имән агач каты агач,
Каен агач чырагач,
Гомерлек ярларым бирдем
Военкомат сорагач.

Урта Баграҗ авылында Федора Николаевна Краснова (1949 елгы, тумышы белән Урта Баграҗдан) башкарганнан язып алган аш-су мәҗлесе җырлары – шулай ук традицион кыйммәтләрне бүгенгә җиткерүе белән истәлекле. Традицион кыйммәт дигәндә бу очракта кыска лирик җырлар гына түгел, керәшеннәрдә гомумән аш-су табыннарының тоташ җыр белән үрелеп бару күренеше югалып бетмәгән булу да күздә тотыла. Кыска җырларда шул як топонимикасы телгә алына, авылның төзелеше, елга-күлләренең урнашуы, халыкның көнкүреше күзаллана:

Баграж суларының басмасы
Узып барганнарда йөрергә,
Ерак араларны якын итеп,
Наруш килдем сезне күрергә.
Утырган да үрдәк, ай, утырган
Оясына мамык тутырган,
Өстәл башларына ямьле итеп,
Туганнарым килеп утырган.
Синең чәчкәйләрең бик көд(е)рә,
Нинди тарак белән тарыйсың?
Йөргән җирләреңдә бик мактыйлар,
Нинди сүзең белән ярыйсың?

Аш-су мәҗлесләре вакытында мондый җырларның һаман да җырлануы лирик җырларның бүгенге көндә дә актив жанр төре булуын ассызыклый. Әмма шунысы бар: җитмеш елга якын элек, әйтик, бер авылдан һәм бер информанттан гына да Х. Мәхмүтов, Х. Курбатовлар,

мәсәлән, берничә дәфтәрдә җыр тексты язып алган булган. 126, 231әр берәмлек җыр кергән берничә дәфтәр бүгенге көндә ТӘҺСИнең Язма мирас үзәгендә саклана. Ул вакытта язып алынган текстлар шулай ук 13 томлык «Татар халык иҗаты»ның җыр томнарына да кертелгән. Бүгенге көндә кыска лирик җырларны актив жанрлар рәтендә санасак та, заманына күрә аларның да ярлылануын, фольклор иҗатның бик нык саегуын искәртми булмый. Экспециядә шәхсән үзем язып алган кыска җырлар саны җиде дистә ел элеккеге белән чагыштырганда бик аз. Бу, әлбәттә, хәзерге экспедициянең комплекслы үтүе һәм бер информантка аерым игътибар биреп, аның белән аралашу вакытының чикләнгәнлегенә дә бәйле. Халык җырлый, әмма җитмеш ел элек башкарылган строфаларны сирәк информант исенә төшерә. Шунысы куанычлы: борынгыдан килгән җырлау традициясе бүген дә исән, халык җырлары бар һәм җырлана.

### Зәйнең һәр карышы риваять сөйли

Тарихи һәм тарихи-топонимик риваятьләр – Зәй районы татар авылларында иң еш очрый торган жанр төре. Информантлар гадәттә – шушы авылда гомер итүчеләр, күпчелекнең әти-әниләре, әби-бабалары ук шушы туфрактан. Үз авылының исеме каян килеп чыккан, бирегә иң беренче кемнәр килеп утырган, авыл нинди тарихи вакыйгалары белән мәшһүр, тавы, күлләре, чокырлары ни өчен нәкъ менә шул исем белән атала – бу мәгълүматларны халыкның риваять итеп сөйли торган истәлекләреннән, хикәятләреннән табарга мөмкин. Авылның тарихын, кешеләрнең яшәешен, табигать белән мөнәсәбәтләрен, тарихи шәхесләрне, үткәндәге вакыйгаларны гәүдәләндерә торган, кайвакыт генеалогик мәгълүматлар да бирә торган мондый төр үрнәкләр Зәй районында авыл саен язып алынды. Мәсәлән:

«Әткәйләр сөйләве буенча, Рәхимкол бабайдан алда монда хәзерге Сарман ягыннан Кадермәт килеп утыра. Аннан соң икенче нәсел хәзерге Чаллы ягыннан килә. Куады нәселе.



Анысы безнең әнкәй ягыннан нәсел. Ә Рәхимкол – әткәй ягыннан безнең нәсел. Рәхимкол бабай Мамадыш өязе Югары Ушмы авылыннан качып күченеп утырган икенче кат чукындырулар вакытында. Беренче килеп утырган Кадермәт исеме белән авыл Кадер авылы дип атала». (Кадер (риваять) // Татарстан Республикасы Зәй районы Кадер авылында Илсур Ситдыйк улы Әюповтан (1951 елгы, тумышы белән Кадердән)).

Түбән Биш авылында Венера Степановна Захарова (1955 елгы, тумышы белән Түбән Биштән) тарафыннан сөйләнгән истәлекне дә бүгенге заман риваятьләре исемлегендә карыйбыз. «Биш авыл» дигән исем белән язып алынган әлеге үрнәктә авыл исеменең килеп чыгышы, элекке һәм хәзерге табигате, монда яшәп киткән әлгәрләр турында сөйләнә, татарларның чукындырылу тарихына да ишарә ителә, бүгенге көндә авылның хәле-халәте хакында бераз мәгълүмат җиткерелә:

«Биш авыл турында риваять бар. Биш елга булган. Хәзер ул елгалар кипкән инде, сулары юк. Элек гөрләп аккан елгалар булган болар. Чөгермә елгасы дигәненең генә исемен беләм, анысы да кипте. Кипкән елгалар бишесе дә.




Бу елгалар барысы да Зәй кушылдыгы Зичә елгасына коя иде. Зичә – венгр телендә төлке дигән сүз, элек монда мадарлар яшәгән диләр бик борынгы заманда. Менә шул Зичәгә коя торган булган биш елга. Пустошит дигән авыл бар. Биш су башы дигәннән ул. Менә шул биш елганың башында утырганга Пустошит – Бишсубашы. Ә Биш авыл биш елганың түбәнге очында утыра, шуңа аны Түбән биш авылы дигәннәр. Бу зур авыл. Монда 11 еллык мәктәп. Гомер-гомергә тирә-юнь авыллардан да монда килеп укыганнар. Керәшеннәр дә яши. Татар очы аерым. Мәчет булган һәм бар. Элек авылда церковно-приходная школа булган. Архив материалларында Түбән Биш авылы 1748 елдан искә алына башлый. Ул аңа кадәр күп элек булган».

Карман авылы Хәниф Фатыйх улы Шәрәфиевтан (1951 елгы, тумышы белән Буракиртәнеке) язып алынган «Карман» дип исемләнгән истәлектә дә тарихи, топонимик яктан кызыклы:

«Бу авылның исеме башта Кара урман булган. Куе урман янәшәсендә булганга шулай атаганнар. Кара урманнан карурманга, аннан, кыскарып, Карманга әйләнгән. Карман дигәне авылга исем булып калган. Мөселман татар авылы. Электән мәчете булган. Мәдрәсә дә булган. Карман төрле елларны үткән ил белән бергә. Бояр булган монда, аңа эшләгәннәр. Тегермәне булган. Әтиләр бәләкәй чакта да булган әле тегермән. Урманы каршыда гына. Табигате матур. Чишмәләре бар. Гомәр чишмәсе, Садыйк чишмәсе бар. Бүләк су буе диләр. Бер егет кыз алырга дип килгән дә язгы суда бүләкләрен агызган елга аша чыкканда. Шуңа Бүләк су дигәннәр ул елганы. Хәзер алай шәп төшми инде урман суы. Элек хәтәр иде. Ургылып су төшә иде. Чияле тау, Ябышкан чокыры, Каланча тавы, Карман тавы, Таш юл (Катерина юлы) – атамалар төрле. Бар да Карманныкы».

Зәй районында тупланган хәзерге риваятьләрдә тарихи контекстның үзгәрүе һәм яңа элементларның өстәлүе ачык күренә. Зәй информантлары авыллары тарихы турында яратып, горурланып сөйлиләр. Тарихны белү, риваять итеп сөйли алу бу тирәләрдә халыкның борынгы чорлардан ук яшәве белән аңлатыла. 1773 елда Зәй шәһәрчеге казаклары, Зәй янындагы Аксар, Никольское, Мәлем, Сәвәләй,

Кабан-Бастырык авыллары крестьяннарының Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышын зур өметләр белән котеп алулары һәм үзләре дә Нагайбәк Әсәнов отрядына кушылып сугышулары билгеле. Бу вакыйгалар халыкта әле дә риваятьләрдә искә алына:

«Урта Баграҗ авылының Кашкатау дигән җирендә Питрау үтә. Бик текә тау булган ул элек. Агачы-фәләне булмаган. Кашкатау үзе урман эчендә утыра. Бик элек астында ниндидер авыл булган дип тә сөйлиләр. Ул авыл хан заманында ук таралган инде. Аның кешеләре тирә-юнь авылларга нигез салып, күчеп утырганнар. Кашкатаудан ерак түгел, шуның тирәсеннән генә юл үтә. Бишавылга табарак ул юл. Какшатау үзе һәм аның тирәсеннән үтә торган юл хан каланчасы белән истәлекле. Шул юлга куйган булганнар каланчаны. Кашкатау итәгеннән Пугачев үз гаскәре белән узган дип сөйлиләр. Ул каланча Пугачевтан күп алда утырган монда. Нindидер бер хан туктала торган урын булган ул элек. Туктамыш хан диләр. Борын заманнарда хан җирләре булган бит инде бу тирәләр бар да». (Кашкатау, хан каланчасы һәм Пугачев // Урта Баграҗ авылы, Федора Николаевна Красновадан (1949 елгы, тумышы белән Урта Баграҗдан)).

## Рухи ядкәрләр – яңа заманда

Халыктан сораштырулар нәтиҗәсендә, җырлардан, авыл турындагы риваятьләрдән тыш, Зәй экспедициясендә халыкның акылын һәм тормыш тәҗрибәсен, әхлакый нормаларын чагылдыра торган берничә мәкаль, әйтем һәм табышмакка юлыктык. Шулай ук халык иҗатының кече жанрларыннан санала торган тыюлар күпләп язып алынды. Халык уеннары, имләүләр, имләгәндә әйтелә торган рифмалы ритмик текстлар, йола фольклоры комплексына кертеп карала торган башка жанрлар һәм элементларны сөйләп бирә алган информантларның булуы – зур куаныч, алар биргән мәгълүматлар татарларның милли-мәдәни тормышын өйрәнүдә өстәмә чыганак ролен үти.

Шушы авылда гына йөри торган һәм бер-берсен белгән кешеләр өчен гаять кызыклы мәзәкләр һәм мәзәк хәлләр, төш юрау текстларының булуы да халык күңеленең җорлыгын, табигатенә хас һәм хас булмаганны аера белүен күрсәтә, халыкның юморын һәм иҗади фикерләү сәләтен чагылдыра. Алар социаль хәлләрне, көндәлек тормышны һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне юморлы формада сурәтләве белән характерлы. Дастан жанрына бәйле мәгълүматларның исә Зәй районында гаять ярлылануын искәртми булмый. Информантлар «Йосыф китабы» турында белә, фабуласын исенә төшереп сөйли, «Сәйфелмөлек» дип ишеткәне бар, борынгы жанрлардан «Сак-Сок» бәетенең берничә юлын хәтерли. Фән-техника казанышлары һәм башка сәбәпләр халыкның рухи мирасы трансформацияләнүгә китергән чор өчен болары да яхшы нәтиҗә. Аның каравы халыкның, аеруча өлкән яшьтәге укымышлы катламның исламга кайту күренеше әһәмиятле. Хәзрәт һәм абыстайлардан дин белән бәйле риваятьләр, багышлау текстлары язып алынды. Халыкның имләү, юрау, тыю, ышану кебек жанрлары да көнкүрештә исламның роле шактый югары булуны күрсәтә.

ТӘһСИ уздырган фәнни экспедициядә җыелган фольклор материалларының перспективалары бик зур. Алар, беренче чиратта, фольклорны өйрәнүче галимнәр өчен кыйммәтле ресурс булып тора. Шулай ук, бу материалларны цифрлаштыру һәм интернетта тәкъдим итү халык иҗатын киң аудиториягә таныту мөмкинлеген бирә. Халыкның рухи ядкәрләре онытылмаган, димәк, фольклорның поэтик бизәкләре дә яңа заманга күчкән. Элек-электән сөйләнә килгән әсәрләр яңа этапта әнә шулай киләчәккә хәрәкәт итә. Авыз иҗаты әсәрләренең һәрберсе мондый нәтиҗәгә лаек дип булмый, әлбәттә, әмма аларның күбесе асылда нәкъ менә вакыт сынавын үтеп, бүгенге көнгә килеп җитә алган булуы белән кадерле.

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**

# *Полиция капитаныннан –* сәнгать остасына

**Рәзинә Исмәгыйлева,**
*журналист*

**Кабатланмас осталык, полиция капитаны дәрәҗәсеннән иҗат юлына күчү, һәм эпоксид сумала ярдәмендә мәңгеләштерелгән иң кадерле мизгелләр... Арчада яшәүче декоратив-гамәли сәнгать остасы Гөлнар Сәгыйтҗанова безнең журнал укучыларын үзе генә булдыра торган, гаять үзенчәлекле иҗаты белән таныштыра. Ул үзенең тырышлыгы, зәвыгы һәм позитив энергиясе белән сәнгать дөньясында якты эз калдыра.**









### Катлаулы һәм мавыктыргыч юнәлеш

Гөлнар профессиональ сәнгать мәктәпләрендә махсус белем алмаса да, күңеленә иң якын, шул ук вакытта катлаулы да, гаҗәеп мавыктыргыч та булган эпоксид сумала сәнгате юнәлешен сайлый. Аның кул астыннан чыккан һәр эшләнмә – чын мәгънәсендә эксклюзив һәм кабатланмас.

Аның иҗат дөньясының чиксез киңлеген күрсәтеп торган әсәрләр арасында:

• Дивар сәгатьләре һәм панно-картиналар (шул исәптән, милли бизәкләрдәге шамаилләр);

• Өй декоры әйберләре: нәфис поднослар, салфетка кую өчен җайланмалар, хәтта нәфис итеп реставрацияләнгән өстәлләр;

• Зәркән бизәнү әйберләре: үзенчәлекле брошкалар, алкалар, беләзекләр;

• Төрле бәйрәмнәр өчен тематик сувенирлар (мәсәлән, чыршы уенчыклары) бар.

«Эпоксид сумала – фантазияне чикләмәгән могҗизалы материал. Аннан теләсә нинди эшләнмә ясап була», – ди оста.

Төсләрнең тирәнлеген һәм сихри матурлыгын бирү өчен, Гөлнар югары сыйфатлы махсус буяулар, перламутр порошоклары, текстур пасталар, ярымасылташлар, пыяла кисәкчекләре, ялтыравыклар һәм хәтта сусаль алтын кебек кыйммәтле материаллар куллана.

### Иҗатка алып килгән кызыклы юл

Гөлнарның бу сәнгать төренә юл ачуы да кызыклы. Тәүге тапкыр ул эпоксид сумала технологиясе белән рәссам Аделина Әкбәрованың интернет-челтәрендәге битләрендә таныша. Бу мавыгу аны «Заманча рәссам» онлайн-курсларын сатып алырга һәм үз осталыгын ныклап үстерергә этәрә.

Ләкин баштарак бар да җиңел генә бармый. Эпоксид сумала – бик четерекле материал.

«Әлбәттә, өйрәнә башлаган мәлләрдә беренче эшләрем килеп чыкмады. Сумаланың күз ачып йомганчы катып китүен күргәч, чын мәгънәсендә гаҗәпкә калдым. Әмма килеп чыкмаса да, күңелем һич сүрелмәде. Киресенчә, яңа төрле иҗат булгангамы, мавыгып китеп, үземне юата-юата, кат-кат эшләп карый идем», – дип искә ала ул үзенең беренче адымнарын.





## Күңел кушканча эшләү

Гөлнар Сәгыйтҗанованың тормыш юлы үзе дә бик үзенчәлекле. Ул Арча районы Хәсәншәех авылы кызы. Мәктәпне тәмамлагач, адвокат булырга хыялланса да, әтисенең киңәше белән Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институтын тәмамлый.

• Хезмәт юлы: институттан соң Арча эчке эшләр бүлегендә хезмәт итә;

• Дәрәҗәсе: 13 ел эчендә лейтенанттан полиция капитаны дәрәҗәсенә күтәрелә;

• Борылыш ноктасы: икенче кызы тугач, 2023 елда, үз теләге белән эштән китәргә карар кыла;

«Күңелем гел иҗатка тартылды. Майлы һәм акрил буяулар белән картиналар да ясап карадым, әмма эпоксид сумаладан ясалган картиналар минем өчен бөтенләй башка дөнья булып ачылды», – ди Гөлнар.

## Гаилә ярдәме – иҗатка канат

Гөлнарның иҗатын аның гаиләсе – ире Алмаз, әти-әнисе Илһам әфәнде белән Рәмзия ханым – тулысынча хуплыйлар.

«Нәселебездә рәссамнар юк. Әтием – фермер, әнием – фельдшер. Иҗатка мәхәббәт кайдан килгән – үзем дә белмим. Әмма кечкенәдән рәсем ясарга ярата идем. Башта әти-әнием моны минем хобби дип кенә кабул итте. Ләкин эшләрем матур килеп чыга башлагач, хәтта сатып алучылар да табылгач, аларның ышанычы һәм горурлыгы артты. Хәзер алар миңа төрле яклап ярдәм итәргә, киңәшләрен бирергә тырышалар. Гаиләм ярдәме – минем иҗади уңышларымның иң зур нигезе», – ди ул.

Иҗатка төннәрен кызганмый Гөлнар. Кызлары Зилә белән Динә йоклагач, аның өчен сихри иҗат мизгелләре башлана. «Иҗат – минем өчен тынычлык, көч һәм илһам чыганагы», – дип аңлата Гөлнар.

## Мәңгеләштерелгән кадерле мизгелләр

Соңгы биш елда ясалган Гөлнарның эксклюзив иҗат җимешләре Россиянең төрле төбәкләрендә генә түгел, хәтта Белорусь, Дагыстан, һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә дә үз хуҗаларын тапкан.







Аңа иң кызыклы, хәтта сентименталь заказлар да килә:

• Кызга егет бүләк иткән чәчәкләрдән панно;

• Бала тугач бирелгән чәчәк бәйләмнәреннән картина-панно;

• Сабыйның УЗИ фотосын, хәтта бала табу йортында бирелгән бәләкәй бирканы сумалада мәңгеләштерү.

## Осталык һәм куркынычсызлык

«Барысын да берүзем, зур ярату белән башкарам», – ди Гөлнар.

Сәнгать остасы, югары сыйфатлы материаллар кыйммәт булу сәбәпле, күпләп эшләнмәләр ясап куя алмый: «Мәсәлән, гадәти акрил буяу банкасы 150-200 сум торса, сумала өчен кирәкле аз гына күләмле буягычның (краситель) бәясе 250-300 сум. Болар өстенә тагын берничә өстәмә компонент алырга кирәк», – ди ул.

Шулай да, бу материаллар белән эшләү игътибарлы һәм пөхтә булуны, саклану чаралары күрүне таләп итә. Чөнки сумала зарарлы матдәләр бүлеп чыгара, шуңа чыдам респиратор, күзлек, нитрил перчаткалар киеп эшләргә кирәк. «Эшләнмә тулысынча әзер булгач, сумаланың кеше сәламәтлегенә бер зыяны да, исе дә калмый», – дип ышандыра оста.

## Яшьләргә киңәш

«Күңелегез тарткан эштән курыкмагыз. Хыялларга каршы барырга кирәк. «Мин булдыра алмыйм», дип туктапып калмагыз. Үзегезне кат-кат сынап карагыз. Яраткан эш көч бирә, канатландыра!» – дип Гөлнар үзенең уңыш формуласы белән дә уртаклаша һәм яшьләргә мәрәҗәгать итә.

Бүгенге көндә Гөлнар Сәгыйтҗанованың иҗат җимешләре белән интернет-челтәрләрдә танышырга мөмкин. «Яраткан эшемне дөрес бәяләсәләр, яисә иҗатым белән кемнедер сөендерсәм – минем өчен иң зур шатлык шул», – ди ул.

Шушы араларда Гөлнар эпоксид сумала белән иҗат итү курслары оештырырга җыена. Кем белә, бәлки киләчәктә аның шәхси иҗат студиясе булыр әле. Уңышлар аңа!

**Фоторәсемнәр Гөлнар Сәгыйтҗанованың шәхси архивыннан**

# ТЕЛӘК ТЕЛИ *беләсезме?*

**Галимҗан Гыйльманов,**
*язучы, әдәбият белгече*



**Әйе-әйе, татарларның яшерен теле бар. Чынлыкта һәр халыкта бар андый тел. Монда әйтергә теләгән атаманы яки фикерне гамәлдә булган гадәти тел кануннары, кулланылыштагы сөйләм нормалары буенча түгел, бәлки, бөтенләй башка, көтелмәгән мәгънәдәге сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләр белән белдерү хакында сүз бара. Төп мәгънәдәге сүзләрне, сүзтезмә-җөмләләрне башка мәгънәдәге сүзләр белән алыштырып, ягъни, яшерен тел кулланып аралашу хакында сөйләшербез бүген.**

Теләк теләү – иң игелекле, изге гамәлләрнең берсе. Ул үзенең тарихы һәм мәгънәсе белән халкыбызның борынгы келәү йолаларына барып тоташа. Рухи мирасыбызның матур бер өлешен тәшкил иткән теләк-әйтемнәр кайчандыр дини догаларыбыз һәм изге ниятләребез урынында кулланылып йөргән. Ә без беләбез: дога ул – илаһи, сихри халәткә ирешеп, Аллаһы Тәгаләнең үзе белән аралашу, аның ихтыярына ирешү, шул рәтвешле, язмышны билгеләргә омтылу, бәхет юрау...

Димәк, теләк – бик җитди гамәл. Ул – рухи категория. Кемгәдер: «Юлың уң булсын!» яисә: «Исән-сау бул!» «Иминлектә, бәрәкәттә яшә!» – дип чын күңелдән, ихлас тойгылар белән әйтәбез икән, үзебез дә сизмәстән, бөтен рухи көчләрне, илаһи тәгълиматларны шушы ниятебезгә җәлеп итәбез дигән сүз. Борынгылар: «Ихлас теләк – Ходай ихтыяры», – дигәннәр. Шуңа күрә, теләк теләгәндә, изге догалар укыган чакта башкара торган йола-гамәлләрне башкарганнар. Әйтик, яңа эшкә керешкәндә яисә берәр ният кылганда борынгы бабаларыбыз шундый теләкләрне әйткәннәр:

«Дәвер белән дәүләт бир, тәүбә белән тәүфикъ бир, хәерле эшкә хәрәкәт бир, ашымызга бәрәкәт бир!»

«Хыял-ниятемне, көч-куәтемне дошманнар алмасын, башлаган эшем ярты юлда калмасын, йөрәгемне дәрт-ялкын ялмасын!»

## ҮЗ-ҮЗЕҢӘ (ЯИСӘ ЯКЫННАРЫҢА) САУЛЫК-СӘЛАМӘТЛЕК ТЕЛӘҮ

Иң мөһим теләкләрнең берсе, әлбәттә. Аны без көн саен кабатларга тиешбез. Шундый текстларның берсе аеруча популяр булган:

«И Тәңрем, И Ходам! И Раббым! И Аллам! (бу бөек, изге атамалар телдә синонимнар рәвешендә йөриләр һәм һәр теләк алдыннан кабатланып әйтеләләр)

*Тәнемне саулыкта тот!*
*Колакларымны саулыкта тот!*
*Күзләремне саулыкта тот!*

*Кул-аякларымны саулыкта тот!*
*Йөрәк-бавырымны саулыкта тот!*
*Эчке әгъзаларымны саулыкта тот!*
*Кабер газабыннан үзеңә сыендыр!*
*Син минем өчен бердәнбер!*
*И Раббым, сакла мине!»*

Бу теләк-әфсен Мөхәммәт пәйгамбәр хәдисләренең берсеннән үзгәртелеп, тулыландырып алынган булырга тиеш. Менә ул хәдис:

«Йа Раббым, тәнемне саулыкта тот, йа Раббым, колакларымны саулыкта тот, йа Раббым, күзләремне саулыкта тот, йа Раббым, кабер газабыннан үзеңә сыенамын. Юк синнән башка бүтән Тәңре!»

## СӘФӘРГӘ, ЮЛГА ЧЫККАНДА ӘЙТЕЛӘ ТОРГАН ӘФСЕН-ТЕЛӘКЛӘР

Аларны сәфәргә кузгалыр алдыннан, «Әгузе бисмилла»ны әйтеп, «Аятел-көрси»не укып әйтәләр.

«И Раббым! Мине Үзеңә генә сәҗдә кылучылардан итеп, Үзеңнән башка мохтаҗ итмичә, бу сәфәремне уңышлы кылсаң иде!»

«И Раббым! Бу сәфәремә мин Сиңа ышанып, үземне Сиңа тапшырып чыгам. Син миңа үзеңнең рәхмәтеңне сал, Хозыр галәйһиссәламне юлдаш кыл, Зәнки бабайны сакчы кыл!»

«И Раббым! Мине үзеңнең рәхмәтеңнән, пәйгамбәребезнең шәфагъеннән (шәфкатеннән) мәхрүм итмә, Хозыр галәйһиссәламнең култыгы астыннан, Җәбраил галәйһиссәламнең канаты астыннан чыгарма!»

«И Раббым! Синең кушканнарыңны үтәп, тыйганнарыңнан тыелып, шушы сәфәремнән юлларым, эшләрем уң булып, исән-сау әйләнеп өемә, илемә кайтырга насыйп әйләсен иде, Үзеңнән башкага мине мохтаҗлык кылмасаң иде. Амин!»

Шул рәвешле тормыш-яшәешнең һәр өлкәсенә, һәр кылган гамәлгә карата илаһи әфсен теләкләр булган. Теләкләр – магик мәгънәгә ия афористик жанр. Гали Рәхим, соңрак Хуҗи Мәхмүтов теләкләрне алкышларга һәм каргышларга аерып карыйлар. Алкышлар – изге теләкләр, Алар, мәсәлән, казахларның рухи мирасындагы алгысларга, якутлардагы алгыс тылларга тәңгәл киләләр. Алкышлар кеше тормышындагы әһәмиятле вакыйгалар вакытында, шатлык-куаныч килгәндә, уңышка ирешкәндә, башка кайбер очракларда хуплау, теләктәшлек белдерү йөзеннән әйтеләләр. Каргышлар – дошман тарафка юнәлтелгән яман теләкләр, шулай ук каршы якның каргышын үзенә кире кайтару өчен әйтелә торган сүзләр. Кыскасы, теләкләрдә сүзнең тылсым көче ярдәмендә табигатьтәге ияләргә, төрле авыруларга, дус яки дошман кешеләргә тәэсир итү, яхшылыкка изгелек кылу, явыз затларның зыяныннан котылу максаты күз уңында тотыла.

## ТУЙ АЛКЫШЛАРЫ

Яшь киленгә әйтелә торган теләк: «Алгы итәгеңне бала бассын, арткы итәгеңне мал бассын!»

Туй чәкчәгенә (туй төшенә) акча алганда әйтелә торган теләк: «Яңа туй булсын, чәкчәк (төш) күңелле (татлы) булсын, һәммәгез дә озын гомерле булсын!»

Туй бүләкләрен алкышлау: «Яңа туй булсын, сөлгеләре буй булсын, бүләкләр мул булсын, бишектә ул булсын!»

Яңа киемне алкышлау. Берәр кеше өстендә яңа кием күргәндә әйтелә торган теләк: «Җылы (эссе) тәнеңдә тузсын!»

«Итәккә – итәк, җиңгә – җиң, якага – яка!»

## КҮМӘК ЭШНЕ (ӨМӘНЕ) АЛКЫШЛАУ:

*Башлыйк теләкне,*
*Күтәрик беләкне,*
*Кояш, шаһит бул!*

*Башлыйк эшне,*
*Җыйыйк көчне,*
*Кояш, шаһит бул!*

*Кояш – сөңге буе,*
*Илдә – хезмәт туе,*
*Кояш, шаһит бул!*

## «СӨЕНЧЕ» АЛКЫШЛАРЫ

Нинди дә булса яхшы хәбәргә сөенче алып килгән кешеләргә каршы шаяртыбрак әйтелә торган әфсен теләкләре хакында сүз бара. Менә аларның берничәсе:

*– Сөенче!*
*– Сөенчесенә уң колагың үзеңә!*

*– Сөенче!*
*– Сөенчесенә Сөләйман сыбызгысы!*

*– Сөенче!*
*– Өстең-башың киенче!*

*– Сөенче!*
*– Сөенчегә – бер күлмәк!..*

## ТӨЧКЕРГӘЧ ӘЙТЕЛӘ ТОРГАН ТЕЛӘК-ӘФСЕННӘР

Төчкергәч әйтелә торган теләк-әфсеннәр дә татарларның йола мирасында шактый күп җыелган. Иң элек шуны искәртергә кирәк: мөселман татарлар, үзләре төчкерсә яисә кемнеңдер төчкерүенә җавап итеп: «Әлхәмделүлләһ», – дип куялар. Хәзер без еш кына: «Сәламәт бул!», «Шифага булсын!» яисә «Шифага китсен!» – дип әйтәбез. Ләкин бик борынгы әфсен такмаклары да очрый әле. Мәсәлән:

*– Әптчи!*
*– Әнә килә карт песи! –*
*Койрыгы төйнәлгән,*
*Балаларын төйнәгән!*

*– Әптчи!*
*– Әнә килә карт песи! –*
*Тешләре тимер кебек,*
*Күзләре күмер кебек...*

*– Әптчи!*
*– Әнә килә карт песи! –*
*Койрыклары без кебек,*
*Ике күзе куз кебек...*

Бу такмакларның көче шунда: алар төчкергәндә өрелеп чыккан җан-котны үз урынына куып кертә, имеш.

Каргышлар – алкышларга каршы якта торган, негатив тойгылар, теләкләр белән бәйле жанр төре. Аның да үз формалары, мәгънәви системасы, фәлсәфәсе бар. Бу турыда озаклап сүз куертып тормыйча, борынгыдан килүче берничә каргыш формасы белән чикләнәбез:

*«Кояш орсын!»*
*«Күк ишелсен!»,*
*«Ризык күрмә!»*
*«Баскан җирең убылсын!»*
*«Җен суккыры!»*
*«Җир йотсын!»*
*«Яшен суксын!»*
*«Шайтан алгыры!»*
*«Кул-аякларың корысын!»*
*«Җаның бугазыңа килсен!»*

## БЕЗ БҮГЕН ТЕЛӘК ТЕЛИ БЕЛӘБЕЗМЕ СОҢ?

Теләк-ниятләребезне әйткәндә туган телебездәге мөмкинлекләрне, җан-рухыбыздагы илаһи потенциалны дөрес кулланабызмы? Тагын бер мәртәбә игътибар итик әле: сөйләм телебездә нинди теләк-әйтемнәр йөри соң? Аларның мәгънәсе ихлас ниятләребезгә туры киләме?

Халык арасында таралган җырлардан башлыйк. Һәр ике җырның берсендә татар кешесе үзенең газиз анасына яисә сөйгән ярына: «Мәңге яшь булып кал!» – дип теләк тели. «Картайма бер дә!» – дип тә җибәрә. Хәзер шушы теләкнең мәгънәсе хакында уйланыйк. «Мәңге яшь булып кал» яисә «Картайма» дигән сүзләр артында вакытсыз өзеләчәк гомер юрау белән бәйле авыр тойгылар ята түгелме?

Борынгылыкта кара магия белән бәйле бу теләк урынына «Матур картлык телим!» («Матур килеш картай!», «Бәхетле картлык насыйп булсын!») яисә «Күңелең белән яшь булып кал!» («Күңелеңнән яшьлек китмәсен!») дигән әйтемнәр кулланганнар.

Тагын бер бик җитди ялгышлык. Без еш кына якыннарыбызны юатканда: «Җаның тынычлансын!» яисә «Җан тынычлыгы телим!» – дибез. Бу сүз дә изге ният белән әйтелә, әлбәттә. Әмма мәгънәсе төгәл үк түгел. Дөресе: «Күңел тынычлыгы телим!», «Күңелең тынычлансын!» Җанның тынычлануы шулай ук вакытсыз гомер өзелү белән бәйле. «Тынгысыз җан телим!», «Тыныч күңел телим!» дигән теләкләрдә бу әле аңлашыла. Әмма җанның тынып, тынычланып калуы борынгылыкта фаталь мәгънәгә ия булган. Күңел белән бөтенләй башкача. Ул күбрәк рухи халәт, кәеф белән бәйләп каралган. Күңел тынычлыгын борынгылар Ходай ихтыярына, бәхиллеккә, игелеккә, бәхеткә ирешү тойгысы белән бәйләп караганнар, һәм ул иң көчле һәм изге теләкләрнең берсе булган.

Тагын бер хата: без якыннарыбызга йокы алдыннан: «Тыныч йокы!» яисә «Тыныч йокла!» – дип әйтергә яратабыз. Телибез-

ме-теләмибезме, шул ук фаталь мәгънә монда да килеп керә. «Тыныч йокы» дигән гыйбарә борынгы ышануларда «үлем йокысы» мәгънәсендә йөргән. Ягъни, җансыз, сулышсыз йокы, бакый дөнья йокысы... Мәрхүмнәрне соңгы юлга озатканда да: «Тыныч йокла», – дибез ләбаса. Русларда «Спокойной ночи!» дигән сүз бар бит, дип әйтүчеләр булыр. Ләкин шуны онытмыйк: русларның «спокойный» сүзендә магик мәгънә бөтенләй юк диярлек. Һәр халыкның үз ышанулары, үз ырымнары.

Бездә «Тыныч йокы» сүзен алыштырырдай әйтемнәр бар. Татар элек-электән йокы алдыннан: «Тәмле йокы!», «Тәмле төшләр!» дип теләк теләгән. Шунысы кызык: бу теләкне без инглиз аристократларының этик системасында да, Кытайда яшәүче гади халык сөйләмендә дә очратабыз.

Теләк теләгәндә, халык ышануларыннан килүче сихри-магик мәгънәләренә төшенеп тормыйча, нинди генә образлар кулланмыйбыз! Ә бит аларның кайберләрен борынгылыкта телгә алырга да ярамаган. Мәсәлән, үз язмышларын сәхнә белән бәйләгән дус-ишләр арасында «Кәккүк кебек моңлы бул» дигән теләк-әйтемне очратып гаҗәпкә калганым булды. Башка кошлар оясына үз балаларын калдырып йөрүче, саный-саный «кеше гомерен кыскартучы» бу кош әйбәт теләк өчен образ була алмыйдыр, минемчә.

Элек-электән «аккош» символы да теләкләрдә сирәк кулланылган. Аның сәбәбе дә халык ышануларыннан эзләргә кирәктер. Билгеле булганча, аккошлар үз гомерләрендә бер генә кош белән парлаша. Фаҗигагә очрап яисә башка берәр сәбәп белән парсыз калса, гомере буе ялгызлыкка дучар булып, каңгырып, моңланып-сагышланып йөри ул. Кеше үз тормышында шушы аккош хәленә калмасын, дип, бик теләргә кушмаганнар «аккошлы» теләкләрне. «Аккош гомере телим» дигән теләк тә авыр теләкләрдән санала. Шул ук ялгызлык, сагыш, чарасызлык теләү кебек бу. Җир йөзендә берничә ел, хәтта берничә көн, сәгать кенә яшәп китә торган «сандугач», «былбыл», «күгәрчен», «күбәләк» гомере теләп әйтелгән җылы сүзләр дә шомлы тойгылар уята. Җырдагыча: «Кояш гомере телим мин, әнием сиңа!» – дип әйтеп була ласа. Йолдызлы төндә бер-берсенә сыенышып утырган яшьләр авызыннан: «Ә-ә-нә теге күктә атылган йолдыз кебек якты бул, киләчәгең шул йолдыз кебек нурлы булсын!» – дигән теләк сүзен үземнең ишеткәнем бар. Ул йолдыз бик күп еллар элек атылган, сүнгән бит инде. Аның бүгенге кеше гомеренә, бигрәк тә аның якты киләчәгенә бернинди дә катнашы юк. Бу да нindидер күңелсез, шомлы юрау.

Бер уңайдан, сөйләм телебезгә килеп кергән, элек халык арасында тыелып йөргән кайбер магик сүзләр хакында да әйтергә кирәктер. Аларның иң күп кулланылганы «уф» сүзе белән бәйләнгән. Без, адым саен зарланырга яратабыз: «Уф!» яисә: «Уф, Алла!» – дибез. Ә бит аның гарәп телендәге мәгънәсе: «туйдым». «Туйдым!» (дөньядан, яшәүдән, синнән...), «Алладан туйдым!» – дип, үзебезнең язмышыбызга авырлык алабыз түгелме соң? Ә бит элек-электән халык бу сүзнең тыелган булуын белгән:

*«Уф!» дияргә ярамый,*
*«Уф!» дияргә ярамый.*
*Янган йөрәк яна икән,*
*«Уф!» дигәнгә карамый...*

«Китәм» дигән сүз белән дә сак булырга кирәк. Теләкләрдә, юрауларда, әйтемнәрдә шулай ук тыелган сүз. Халык борынгылыкта бу сүзнең мәгънәсен «бакый дөньяга китү» дип аңлаган. Аның урынына «киләм», «барам», «кайтам» сүзләрен иркен кулланып була лабаса.

Кызганыч, балаларын «Эттән туган!», «Чукынган тәре!», «Чукынчык!», «Башың беткере!», якыннарын, ирләрен, хатыннарын «Җир бит!», «Хәерсез!», «Имансыз!», «Дөмеккере!» дип орышкан кешеләрне дә тормышыбызда еш очратабыз. Бер мәртәбә булса да тукталып уйлап карыйлар микән алар бу сүзләрнең асыл мәгънәсе хакында?!

Укучы колагына әйтер сүзем шул: матур, изге теләкләрне үз-үзебезгә, якыннарыбызга, дус-ишләргә, милләттәшләребезгә, һәр очраган адәми затка ешрак әйтик. Бу сүзләрнең кайчандыр борынгы бабаларыбызның күңел догаларыннан төшеп калган кыйпылчыклар, кәлимәләр булуын онытмыйк! Ә каргышлы, рәнҗешле теләкләрдән, ничек кенә авыр булса да, тыелып калырга өйрәник! Теләкләрнең изгесе дә, каргышлысы да кайчандыр үзебезгә әйләнеп кайтачагын онытмыйк!

# Әлифба рухи азыгыбызның башлангычы

*1999 елда Арча педагогия көллиятендә дөньяда бердәнбер булган «Әлифба» музее, төгәлрәге, «Дөнья халыкларының букваристика һәм әлифба сәнгате музее» ачыла. Ул күренекле галим-педагоглар – Татарстанның атказанган укытучылары, Россия Федерациясе халык мәгариф отличниклары, Каюм Насыйри исемендәге премия лауреатлары, Әхмәтһади Максуди, Мөхетдин Корбангалиев, Габбас Сәйфуллиннарның традицияләрен дәвам иттереп, «Әлифба» китабы һәм 40тан артык методик һәм фәнни хезмәт авторлары Сәләй Вәгыйзов һәм Рәмзия Вәлитоваларның исемнәрен мәңгеләштерү максатыннан оештырыла. Музейның педагогия көллиятендә урнашуы очраклы түгел. Алар, Казан педагогия институтын тәмамлап, Арчага эшкә кайталар һәм, лаеклы ялга киткәнче, педагогия училищесында татар теле һәм әдәбияты фәненнән укыталар.*

*Бүгенге көндә музейда 1410 экспозиция бар. Шулай ук күчмә күргәзмә, экскурсоводлар мәктәбе эшли, музей педагогикасы буенча лекцияләр укыла, музейда төрле чаралар һәм елына 200дән артык экскурсияләр үткәрелә, 2500 кешене кабул итә. Музей чит ил вәкилләрен дә кызыксындыра.*

*1999-2001 елларда музейны – Хөсәен Фатыйх улы Хәйруллин, 2001-2017 елларда – Сания Сибгатулла кызы Камалетдинова, 2018 елдан бүгенгәчә **Дамир Гыйлемшәех улы Таҗиев** җитәкли. Журнал укучыларыбызны да музей белән ул таныштыра.*




«Әлифба» музее өч залдан тора. Беренче залда дөнья халыкларының әлифбалары тупланган. Сигез экспозициядә 160 әлифба куелган. Алар дөнья халыкларының 76 телендә. Музейда барысы 300гә якын әлифба бар. Алар географик принцип белән төзелгән, мәсәлән, Татарстанга чиктәш ре-











**Рәмзия Вәлитова һәм Сәләй Вәгыйзов**

спубликалар: мари, чуваш, удмурт; төньяк регионнар, биредә кавказ халыклары; аннары 15 союздаш республика, биредә 100 ел элек булган әлифбалар; шулай ук Европа телләрендә, Азия халыклары әлифбаларын күрергә мөмкин.

Кыскасы, музейда алман, чех, румын, испан, инглиз, француз, гарәп, фарсы, иврид, грек, болгар, молдован әлифбалары белән танышырга була.

Арча педагогия училищесын тәмамлаган, «Әлифба» авторы Рәмзия Вәлитованың укучысы булган, татар әдәбияты классигы, халык язучысы Гариф Ахуновның: «Дөньяда ике могҗиза бар: берсе – чишмә, икенчесе – Әлифба» дигән сүзләре бар. Чыннан да чишмә тәнебезгә азык бирсә, әлифба безнең рухи азыгыбызның башлангычы.

Икенче зал татар язуының һәм татар әлифбасының килеп чыгу тарихына багышланган. Россиядә яшәүче татар халкы 1927 елга кадәр гарәп имлясында яза, 1927-1939 елларда латин графикасын куллана, ә 1939 елдан кириллица язуына күчә.

Сәгыйть Хәлфин тарихка беренче татар әлифбасын төзүче булып кереп кала, гарәп графикасында булмаган өч п, ж, ч хәрефләре өсти. Үзе ул Казан гимназиясенең татар теле укытучысы була. Музей экспозициясендә беренче әлифба битләре дә урын алган.

1804 елда Казан Император университеты ачыла. Биредә типография булдырыла. Моңарчы кулдан язылган әлифбаларны бастыру мөмкинлеге дә барлыкка килә.

Икенче залда әлифбаларны күпләп бастырып таратучы галим Шиһабетдин Мәрҗанигә урын бирелгән. Шулай ук биредә рус азбукалары да куелган.

Татар әлифбасын таратуда зур өлеш керткән галим Әхмәтһади Максудиның гарәп графикасында язылган «Мөгаллим әвәл» (Беренче укытучы) һәм «Мөгаллим сани» (Икенче укытучы) әлифбаларын да музейда күрергә мөмкин.

XX гасыр башында төрле әлифбалар чыга. Тәрки әлифба, «Юл башы» әлифбасы, Мөхетдин Корбангалиевның татар әлифбасы... Монысы 1945 елга кадәр төп әлифба булып тора. Аннары аны Габбас Сәйфуллин әлифбасы алыштыра. Әлеге әлифба белән Сәләй Вәгыйзов һәм Рәмзия Вәлитовалар әлифбасына кадәр укыталар.

Өченче зал – төп зал. Биредә әлифба авторлары ирле-хатынлы Сәләй Гататович Вәгыйзов һәм Рәмзия Гыйләҗевна Вәлитоваларның тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлекләре белән танышырга мөмкин.

Сәләй Вәгыйзов (1908-2005) Самара өлкәсенең Камышлы районы Байтуган авылында туа. Алты айлык вакытта, әти-әнисез калган малайны, авылның баласыз гаиләсе асрамага ала. Аңа үзләренең фамилияләрен биреп, исемен дә үзгәртәләр. Киләчәктә татар әлифбасы авторы булачак Сөләйман Хәлиуллин шулай Сәләй Вәгыйзов булып китә.

Булачак хатыны, 1914 елда Эстәрлетамак шәһәрендә туып үскән, Рәмзия Вәлитова (1914-2002) белән алар Казан педагогия институтында танышалар һәм дуслашып китәләр. 1936 елда алар өйләнешәләр. Институтны тәмамлаганнан соң, 1937 елда Рәмзия Вәлитова һәм Сәләй Вәгыйзов Арча педагогия училищесына эшкә юллама алалар.

Дүрт елдан сугыш башлана. Сугышка кадәр ике балалары Римма белән Камил туа. 1942 елда Сәләй фронтка китә һәм бер елдан Харьков янындагы көчле сугышлардан соң, алар, чолганышта калып, әсирлеккә төшәләр. Җиңү язында Сәләй Вәгыйзовны америкалылар азат итсә дә, Советлар Союзы чиген узуга НКВД гаскәрләре әсирләр белән



**Уртада – «Әлифба» музее җитәкчесе Дамир Таҗиев**

тулы эшелонны үз кулларына ала. Сәләй Вәгыйзовның алдагы ун елы бик аянычлы үтә: сөргендә Печора тирәсендә юллар сала, урман кисә.

Рәмзия, балаларын ияртеп, ире янына ике тапкыр бара. Нәтиҗәсе – аны педучилищедан эштән куалар. Сәләй хатынына: «...Миннән ваз кичсәң, сиңа җиңелрәк булыр», – дип хат яза. Рәмзия үз фамилиясенә – Вәлитовага әйләнеп кайта һәм эшенә кайтарыла.

Ун ел срогын тутырганнан соң Сәләй Вәгыйзов Арчага кайта. Әмма аны укытырга алмыйлар, ул төрле авыр эшләрдә эшләргә мәҗбүр була. Берничә елдан соң аңа Арча районы Мөндеш җидееллык мәктәбендә укытырга рөхсәт бирәләр. Тагын гаиләдән аерылып яшәүләр башлана.

Сәләй Гататовичның тормышындагы борылышны үзенең укучысы, Арча районы халык мәгарифе бүлеге мөдире булып эшләүче, соңрак ТАССРның Мәгариф министры урынбасары Равил Әлмиевич Галиәхмәтов ясый. Ул аны педагогия училищесына укытырга кайтара.

Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитованың бөтен тормышы, хезмәт юлы шушында уза. 1960 елдан башлап, алар «Әлифба» китабын һәм татар мәктәпләре өчен дәреслекләр, уку әсбаплары төзү өстендә эшлиләр.

1968 елда ТАССРның Югары Советы Президиумы Карары белән Сәләй Вагыйзовка «ТАССРның атказанган укытучысы» исеме бирелә. 1988 елда ул К. Насыйри исемендәге премиягә








**Нурания Абзалова Сәләй Вәгыйзовның музей-йортында**

лаек була. Мәгариф өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ушинский медале белән бүләкләнә.

С.Г. Вагыйзов ТАССРның Югары Советы Президиумы рәисе Гали Динмөхәммәтов җитәкчелегендә яңа орфография эшләү өчен төзелгән Дәүләт комиссиясе әгъзасы була, педучилищелар һәм башлангыч мәктәпләр өчен укыту программалары төзүдә катнаша.

Рәмзия Гыйлләҗ кызы Вәлитова да «ТАССРның атказанган укытучысы» (1961 ел), Россия Федерациясенең «Халык мәгарифе отличнигы» исемнәренә, 1988 елда Каюм Насыйри премиясенә лаек була.

* * *

Яшьлекләре авырлыкта үтсә дә, алар бәхетле картлык кичерделәр. Рәмзия Гыйлләҗевна – 88, Сәләй Гататович 96 яшькә кадәр яшәделәр. 30га якын фәнни хезмәт яздылар, татар телен укытуга багышланган ярдәмлекләр чыгардылар.

2016 елда туган авылы Камышлы районы Байтуган авылында Сәләй Вәгыйзовның музей-йорты ачылды. Биредә китап тәкъдим итү кичәләре, дини бәйрәмнәр, күргәзмәләр уздырыла, балалар өчен «Авылның тарихын беләсезме?», «Әби-бабайлардан калган гореф-гадәтләрне саклыйк!», «Әбиемнең серле сандыгы», «Кырларның шифалы үләннәре» кебек викториналар оештырыла. Музей-йортта шулай ук суккан паласлар, ашъяулыклар, сөлгеләр почмагы да бар. Сәләй Вәгыйзовның музей-йортыннан кунаклар өзелми. Ачылышыннан бирле аны Сәләй Гататовичның авылдашы, әлеге музейны оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе Нурания Минсәхи кызы Абзалова җитәкли.

Быел Татарстан китап нәшриятында легендар татар «Әлифба»сы авторлары Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитова тормышына багышланган Лилия Гыйбадуллинаның «Әлиф ләм мим» исемле китабы дөнья күрде.

2018 елда Арчадагы «Әлифба» музее да яңартылды, яңа экспонатлар белән тулыландырылды. Арча педагогия көллияте каршында әлифбага һәйкәл куелды.

Бүгенге көндә яңа, көн таләпләренә туры килә торган әлифбалар языла тора. Ул шулай булырга тиеш тә. Әмма ярты гасырга якын балаларда әхлак сыйфатлары тәрбияләүнең, кеше шәхесенең формалашуының чишмә башы булып торган Сәләй Вәгыйзов һәм Рәмзия Вәлитова язган әлифба китабы үзенең әһәмиятен беркайчан да югалтмас дип ышанам.

**Фоторәсемнәр «Әлифба» музее архивыннан**

# Нәсел тамгалары – халкыбызның уникаль тарихи мирасы

**(Арча районы Наласа авылы халкының XIX-XX гасыр башы нәсел тамгалары үрнәкләре)**

Хәзерге Арча районындагы Наласа авылының XIX гасыр – XX гасыр башында (1845-1919 елларда) тутырылган метрика язулары мәгълүматларына таянып төзелгән нәсел тамгалары таблицасы безнең тарафтан 2012 елда нәшер ителгән Наласа тарихы китабына тәгаенләнгән иде (кара: Гасырлар кичкән Наласа. – Казан: «Ихлас», 2012. – 246 б.). Тик кайбер сәбәпләр аркасында, ул басмага керми калды. Хәзер исә, без аны журнал укучыларына тәкъдим итәргә булдык.

XX гасыр башына тикле авыл муллалары тутырып барган бу метрика язулары Татарстан Дәүләт архивында (204 фонд, 177 тасв.) һәм Уфа шәһәрендәге Башкортстан Милли архивында (И-295 фонд, 9 тасв.) саклана. Тарихи чыганак буларак, алар шуның белән дә кызыклы – бу метрика язуларында борынгы нәсел тамгаларының шактый бай мирасы туплаган.

Гадәттә, мәхәллә (авыл) муллалары елдан-елга тутырып барган метрика кенәгәләре дүрт бүлектән тора: 1) мәхәлләдә агымдагы ел дәвамында туучылар; 2) вафат булучылар; 3) никахлар; 4) аерылышулар. Нәсел тамгаларының күпчелеге никахлар өлешендә тупланган. Чөнки ике яктан да никахта шаһит булып катнашкан «вәли вәкилләр», күп очракта, ул никахларны үзләренең нәсел тамгалары белән беркетә-раслый торган булган.

Әлегәчә, борынгы нәсел тамгалары халкыбыз тарихында аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе булып кала. Югыйсә, алар татар этногенезын, нәсел-ыру тарихларын өйрәнүдә әһәмиятле чыганакларның берсе буларак саналырга хаклы. Чөнки нәсел-ыру тамгалары гасырлар дәвамында тотрыклы калып, буыннан-буынга үзгәреш кичермәгән диярлек. Шунлыктан, алар нәсел-ыру тарихларын, кешеләрнең нәсел тамгаларын торгызу-барлау эшендә тарихи чыганак буларак кулланыла ала. Мәсәлән, Наласа авылы кешеләренең таблицада китерелгән тамгалары мисалында да бер үк яисә охшаш тамга ияләренең үзара нәсел-нәсаптәш булуы яхшы шәйләнә.

Гомумән, элек халыкта «нәсел тамгаңны күрсәт, ыру агачыңны, нәсел кошыңны бәян ит – шунда мин сиңа кем икәнлегеңне әйтеп бирәм», дигән әйтем кулланылышта булган.



Тамгалы урта гасыр тәңкәсе



Һөнәрчелек эшләнмәсендәге тамга

Ник дигәндә, ул заманнарда һәр төрки ыруның, нәселнең үз символик тамгасы, үз агачы һәм кошы булган (мәсәлән, шәхсән минем үземнең әни ягыннан нәсел тамгам әверннә – Х, кошым – кучәгән, агачым – карагай).

Үз заманында күренекле Уфа тарихчы-этнографы Раил Гомәр улы Кузеев нигез салган белемнәргә, традициягә таянып, күрше Башкортстан галимнәре, төбәк тарихчылары төрки тамгаларны өйрәнүгә, аларны үзләренең хезмәтләрендә файдалануга, популярлаштыруга зур игътибар бирә. Бездә исә, Марсель Әхмәтҗанов, Фәйзелхак Ислаев, Геннадий Макаров кебек аерым галимнәрнең кайбер мәкалә-китапларын исәпкә алмаганда, әлегә бу эшләр берникадәр «аксый төшә».

Гомумән алганда, борынгы төрки-татар тамгаларының ике меңъеллык диярлек тарихы бар! Хәтта ки, хәзерге вакытта киң мәгълүм «таможня» төшенчәсенең килеп чыгышы да нәкъ менә шушы «тамга» сүзенә барып тоташа!

Мөгаен, билгеле тамгалардан иң мәшһүре – ул урта гасыр төрки-татар дәүләтләрендәге идарәче Гәрәйләр династиясенең тарак тамгасыдыр (кара). Хәзерге вакытта ул Кырым татарларының рәсми булмаган туграсы (гербы) буларак та файдаланыла.

Язылыш рәвешләренә карап, нәсел тамгалары аерым төркемнәргә бүлеп йөртелә. Мәсәлән, чәч тарагын хәтерләткәннәре – тарак тамга, сәнәк япьләренә охшаганнары – сәнәк тамга, чүкечне хәтерләткәннәре – чүкеч тамга, капкага охшап торганнары – капка тамга, каз тәпиен хәтерләткәннәре – казаяк тамга, көпчәк, пәрәвез элементларын хәтерләткәннәре – әвернә тамга һәм башкалар.

Нәсел-ыруларның, аерым шәхесләрнең иялек, хокук билгесе буларак, элек нәсел-ыру тамгаларын эш кәгазьләренә, рәсми документларга, эш һәм сугыш кoраллaрына, һөнәрчелек эшләнмәләренә, таңкаларга, ызаннарга һәм башкаларга сукканнар. Алар белән махсус мөһерләр дә (шул исәптән, балдак-мөһерләр дә) ясатканнар.

Азсызыклап, шуны әйтергә була: ерак гасырлардан хәзерге көннәргәчә килеп ирешкән борынгы нәсел-ыру тамгалары – алар халкыбызның йөзек кашына тиң, уникаль тарихи ядкәре, кыйммәтле вә хикмәтле мирасы. Аларны булдыра алганча барлау, истә яңарту һәм киләчәк буыннарга мирас итеп тапшыру – безнең бурычларның берседер.




**Мәкалә авторының нәсел тамгасы нигезендә галим һәм нәкышчы рәссам, Г. Тукай премиясе лауреаты Нәҗип Нәкъкаш эшләгән шәхси мөһере**

Борынгы төрки-татар нәсел тамгаларының бер үрнәге мисалында, аларның хәзерге Арча районындагы мәшһүр Наласа авылы кешеләренә нисбәтле бер өлешен түбәндәге таблицага салып бирәбез. Тәңгәл яисә охшаш тамга ияләренең үзара нәсел-нәсаптәш булу ихтималын күздә тотып, алар монда төркемләп бирелде. Ихтимал, бу авылның бүгенге буын вәкилләренә дә үзара нәсел-нәсаптәшлек мөнәсәбәтләрен барларга ярдәм итәр.

| Тамга ияләре | Метрика еллары | Тамгалар |
|---|---|---|
| Хөсәен Габделлатыйф улы<br>Мифтахетдин Хөсәен улы<br>Шаһиәхмәт Шаһимәрдан улы<br>Сәмигулла Сабит улы<br>Камалетдин Гайсә улы<br>Гатиятулла Гыйсмәтулла улы<br>Сабирҗан Габделгалим улы<br>Шәйхетдин Хөсәен улы<br>Исмәгыйль Ибраһим улы<br>Закир Фазулла улы<br>Закир Валиулла улы | 1848<br>1897<br>1906<br>1907<br>1907<br>1907, 1908, 1917<br>1908<br>1908<br>1891,1918<br>1916, 1918<br>1905, 1918 |  |

## БЕЗГӘ ЯЗАЛАР

| | | |
|---|---|---|
| Галиәхмәт Галиәкбәр улы<br>Гайнулла Хәмидулла улы<br>Габделвәли Габдулла улы<br>Шәриф Ишмөхәммәд улы<br>Сәйфетдин Зәбир улы<br>Мөхәммәдсадыйк Ишмөхәммәд улы<br>Садыйк Габит улы<br>Мохтар Мортаза улы | 1853<br>1857<br>1857<br>1858<br>1859<br>1861<br>1887<br>1889 |  |
| Зәйнетдин Зәбир улы<br>Габделмәҗит Габит улы<br>Корбангали Йортмәмәт улы<br>Сәйфетдин Зәбир улы<br>Таҗетдин Сәйфетдин улы<br>Хөснетдин Хөсәен улы<br>Хәйрулла Әшбәтулла улы<br>Җәләлетдин Нәҗметдин улы<br>Камалетдин Сираҗетдин улы<br>Баһаветдин Шәмсетдин улы | 1845<br>1848<br>1849<br>1858<br>1895<br>1895, 1897<br>1917<br>1917<br>1918, 1919<br>1919 |  |
| Сабит Мәҗит улы<br>Миңнебай Вәлит улы<br>Баһаветдин Шиһабетдин улы<br>Камалетдин Гыймадетдин улы<br>Шәйхетдин Шиһабетдин улы<br>Хөснетдин Камалетдин улы<br>Хәйрулла Миңнебай улы<br>Гайнетдин Камалетдин улы<br>Җәлалетдин Баһаветдин улы<br>Гайфулла Миңнебай улы<br>Галиулла Хәмидулла улы | 1876<br>1881<br>1887<br>1892<br>1889, 1892<br>1892, 1909<br>1904 1906 1919<br>1917<br>1918<br>1919<br>1919 |  |
| Баһаветдин Шиһабетдин улы<br>Шәйхетдин Шиһабетдин улы<br>Хөснетдин Камалетдин улы | 1889<br>1889<br>1906 |  |
| Гыйльман Бикчәнтәй улы<br>Мөхәмметҗан Габделкаһир улы<br>Салих Шәйхетдин улы<br>Шәрәфетдин Шәйхетдин улы<br>Хәйрулла Фәтхулла улы<br>Рәхимҗан Әхмәт улы<br>Сәмигулла Лотфи улы<br>Җәлалетдин Фәтхулла улы<br>Шәрәфетдин Сөлайман улы<br>Шаһгәрәй Гобәйдулла улы<br>Шәмсетдин Садретдин улы<br>Шәмсетдин Сәгыйть улы | 1899<br>1908, 1919<br>1908<br>1908<br>1908<br>1917<br>1918<br>1918<br>1918<br>1918<br>1919<br>1919 |  |

| | | |
|---|---|---|
| Ибраһим Габдерәхим улы<br>Хәсән Сабит улы<br>Гыйззәтулла Нигъмәтулла улы<br>Гали Габдессәлам улы<br>Низаметдин Ихсан улы<br>Шафигулла Габделвәли улы<br>Җәләлетдин Фәтхулла улы<br>Тәхаветдин Сәгъдетдин улы<br>Рәхимҗан Әхмәт улы | 1846<br>1846<br>1853<br>1896<br>1896<br>1906<br>1910<br>1908, 1912<br>1912 |  |
| Гайнулла Гобәйдулла улы<br>Мөхәммәдгалим Йөзлекәй улы<br>Фәтхулла Гобәй улы<br>Әхмәтҗан Мөхәммәтҗан улы<br>Галим Мостафа улы<br>Хәмидулла Заһидулла улы<br>Заһидулла Гайнулла улы<br>Фәйзулла Насыйбулла улы<br>Хәбибрахман Сәйфетдин улы<br>Нигъмәтҗан Галимҗан улы<br>Әхмәтгәрәй Галимҗан улы<br>Хисаметдин Хөснетдин улы<br>Хөснетдин Гайфулла улы<br>Шаһислам Гайнулла улы | 1845<br>1849<br>1858<br>1907<br>1908<br>1908, 1917, 1919<br>1908, 1911<br>1912<br>1914<br>1918<br>1918<br>1919<br>1919<br>1919 |  |
| Хәмидулла Рәхмәтулла улы<br>Гыйззәтулла Рәхмәтулла улы<br>Мөхәммәдзариф Мөхәммәдгалим улы<br>Шәфигулла Габделвәли улы<br>Галим Мостафа улы<br>Вильдан Гыйльман улы<br>Шәрәфетдин Шаһиәхмәт улы<br>Сафиулла Гыйльман улы | 1860<br>1895<br>1905<br>1906<br>1907, 1908<br>1909<br>1910<br>1912 |  |
| Габдесаттар Габдесәлам улы<br>Хөснетдин Фәхретдин улы<br>Насыйбулла Габделгаяз улы<br>Гайнулла Халид улы<br>Әхмәтҗан Габдесаттар улы<br>Мифтахетдин Исмәгыйль улы | 1872<br>1888<br>1891<br>1897<br>1898<br>1898 |  |
| Сәйфулла Сәлим улы<br>Сабит Сәлим улы<br>Халит Хәмит улы<br>Мортаза Мәхмүт улы<br>Вәлиша Хөрамша улы<br>Әхсән Мөэмин улы<br>Шәрәфетдин Ибраһим улы<br>Шәйхетдин Сабит улы<br>Хәбибулла Сәйфулла улы<br>Ибраһим Хәсән улы | 1845, 1857<br>1845, 1857<br>1845<br>1853<br>1857<br>1858<br>1863<br>1863<br>1863<br>1877 |  |

## БЕЗГӘ ЯЗАЛАР

| | | |
|---|---|---|
| Габделвәли Габдулла улы<br>Әхмәт Әбелкасыйм улы<br>Мөхәммәдрәхим Габит улы<br>Бибигариф Әгъзам улы<br>Бәдретдин Әгъзам улы<br>Шаһиәхмәт Галиәкбәр улы<br>Фазулла Хәбибулла улы<br>Йосыф Яхъя улы<br>Рәхмәтулла Габдулла улы<br>Вафа Мөхәммәдҗан улы | 1861<br>1863<br>1873<br>1874<br>1874<br>1874<br>1875<br>1875<br>1876<br>1911 |  |
| Хөсәен Хәсән улы<br>Галиәхмәт Галиәкбәр улы<br>Фәтхулла Хәбибулла улы<br>Габит Гомәр улы<br>Хөсәен Вәлит улы<br>Хәсән Гайнулла улы<br>Мөхәммәдюныс Мөхәммәдйосыф улы | 1851, 1860<br>1857<br>1858<br>1858<br>1860<br>1890<br>1898 |  |
| Габделмәҗит Габделвахит улы<br>Габит Гомәр улы<br>Хәсән Хөсәен улы<br>Мөхәммәдвафа Мөхәммәдҗан улы<br>Мөхәммәдҗан Хөсәен улы<br>Мифтахетдин Садыйк улы<br>Хәкимҗан Мөхәммәдҗан улы<br>Мөхәммәдҗан Хөсәен улы | 1861<br>1861<br>1872<br>1873<br>1905<br>1916<br>1917<br>1917 |  |
| Әхмәт Әлкасыйм улы<br>Мөхәммәдҗан Сәгыйть улы<br>Шаһиәхмәт Шаһимәрдән улы<br>Әхмәди Әхтәм улы<br>Җәлалетдин Мәхмүт улы<br>Шакир Галим улы<br>Хәлиулла Сафиулла улы<br>Мөхәммәдҗан Хөсәен улы<br>Юныс Йосыф улы | 1861<br>1895<br>1895<br>1897<br>1897<br>1905<br>1905<br>1908<br>1919 |  |
| Шәрәфетдин Ишкинә улы<br>Фәтхулла Хәбибулла улы<br>Фазулла Хәбибулла улы<br>Йосыф Мөсәгыйть улы<br>Вәлит Мөсәгыйть улы<br>Җарулла Вәлиулла улы<br>Шафигулла Сафиулла улы<br>Исмәгыйль Йосыф улы<br>Сиражетдин Йосыф улы<br>Гатаулла Фазулла улы<br>Сибгатулла Вәлиулла улы | 1858<br>1861<br>1861<br>1892<br>1892<br>1905, 1906, 1907<br>1908<br>1909<br>1912<br>1913<br>1913 |  |
| Ишмөхәммәд Шәфи улы<br>Сәгыйть Сабит улы<br>Биккинә Гәрәй улы<br>Әхмәт Әбелкасыйм улы<br>Мөхәммәдҗан Галиәкбәр улы<br>Гыйбадулла Габделвахит улы<br>Хәбибулла Фәтхулла улы<br>Йосыф Мөхәммәдрәхим улы | 1851-1860<br>1858<br>1863<br>1872<br>1873<br>1893<br>1903<br>1906 |  |

| | | |
|---|---|---|
| Нигъмәтулла Рәхмәтулла улы<br>Йосыф Мөхәммәдьяр улы<br>Габделфәиз Габдеҗәлил улы<br>Габделвахит Рәхмәтулла улы<br>Мостай Габделфәез улы<br>Шәмси Шәмгол улы<br>Сәйфетдин Сәйфелмөлек улы | 1848<br>1852<br>1858<br>1858<br>1858<br>1863<br>1863 |  |
| Фәхретдин Госман улы<br>Шәфигулла Гыйззәтулла улы<br>Сиражетдин Сабит улы | 1872<br>1890<br>1890 |  |
| Әхмәт Сабит улы<br>Гыйззәтулла Нигъмәтулла улы<br>Миңнебай Сәгыйть улы<br>Фәтхулла Ибраһим улы<br>Насыйбулла Баязит улы<br>Гыйбадулла Гыйззәтулла улы<br>Фәхретдин Хәмзә улы<br>Гатаулла Гыйззәтулла улы<br>Габделвәли Габделвахит улы<br>Шәрәфетдин Нәҗметдин улы<br>Гали Габдессәлам улы<br>Гайнулла Гыйззәтулла улы<br>Һибәтулла Сәйфулла улы<br>Габделвәли Габделкәрим улы<br>Камалетдин Фәхретдин улы | 1860<br>1878<br>1879<br>1881<br>1884<br>1884<br>1884<br>1889<br>1889<br>1889<br>1889<br>1890<br>1890<br>1892<br>1897 |  |
| Тимергали Корбангали улы<br>Мөхәррәм Бикчәнтәй улы | 1857<br>1880 |  |
| Фәтхулла Ибраһим улы | 1890 |  |
| Габделвахит Габделфәиз улы<br>Шәмсетдин Нәзир улы<br>Мөхәммәди Габделвәли улы<br>Вәлиулла Хәмит улы<br>Габделмәҗит Габделвахит улы<br>Миңнебай Вәлит улы<br>Гайсә Гаделша улы<br>Мөхәммәджан Гайнулла улы | 1848<br>1848<br>1857<br>1873<br>1893<br>1896<br>1896<br>1896 |  |
| Гыйззәтулла Нигъмәтулла улы<br>Шәмсетдин Шәмгол улы<br>Сөләйман Идрис улы | 1860, 1861<br>1868, 1872<br>1890 |  |

| | | |
|---|---|---|
| Мөхәммәдшәриф Әмин улы | 1852 |  |
| Вәлит Сәгыйтъ улы<br>Садыйк Вәлит улы<br>Шәмсетдин Таҗетдин улы | 1849<br>1859<br>1876 |  |
| Ишмөхәммәд Ишморат улы<br>Һиббәтулла Габдерәхим улы | 1857<br>1861 |  |
| Гайнулла Рәхмәтулла улы<br>Гыйлаҗетдин Гыймадетдин улы | 1857<br>1917 |  |
| Әхмәт Мостай улы | 1857 |  |
| Фазулла Хәбибулла улы<br>Фәтхулла Хәбибулла улы<br>Габит Гомәр улы<br>Һибәтулла Хәбибулла улы | 1857<br>1857<br>1858<br>1872 |  |
| Нигъмәтулла Рәхмәтулла улы | 1846 |  |
| Шәриф Әмин улы | 1853 |  |
| Һибәтулла Габдулла улы<br>Гобәй Габделгази улы<br>Гали Бикчәнтәй улы<br>Гобәйдулла Габделгаффар улы<br>Гыймадетдин Таҗетдин улы<br>Гыйбадулла Вәлиулла улы | 1857<br>1858<br>1859<br>1863<br>1903<br>1918 |  |
| Мөхәммәдшәриф Әмин улы | 1858 |  |

**Рәшит ГАЛЛӘМ, тарихчы**

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**

# Яшәү белән үлем

(«ТАТАР ГАИЛӘСЕ: ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ҺӘМ ЙОЛАЛАР» КИТАБЫННАН ӨЗЕК)




**Татар гаиләсе: гореф-гадәтләр һәм йолалар / Автор-төзүчеләр: Л.Х. Дәүләтшина, Ф.Х. Җәүһәрова, Н.А. Халиков, О.Р. Хисамов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. – 175 б.: рәс. б-н.**

**Рәссам Рабис Сәлахов, Татарстан Республикасының халык рәссамы**

…Татарлар – дөнья буйлап таралган, зур тарихлы һәм бай мәдәниятле халык, аларның элек-электән төрле этнотерриториаль төркемнәр булып яшәве урынчылыкка бәйле йола-гадәтләрдә төрлелек китереп чыгарган. Әмма бу төрлелек, асылда, бер үк күзаллауларга, матди һәм рухи көнитеш уртаклыгына барып тоташа. Шуңа күрә китапта, гомумән, татар халкына хас булган йола, гадәт, ышанулар барланды, аерым бер очракларда гына аларның кайбер урыннарда күзәтелгән вариантлары тәкъдим ителде.

«Татар гаиләсе: гореф-гадәтләр һәм йолалар» дип исемләнгән, татар халкының гаилә-көнкүреш йолалары асылын аңлатуга йөз тотып язылган әлеге хезмәт бик күпләргә кабат үз нәселләрен барларга, балаларын, оныкларын татар рухында тәрбия кылырга, туган-тумачалары белән дустанә яшәү рәвешен тагын да ныгытырга ярдәм итәр, халкыбызның буыннан-буынга сакланып, әле дә булса үтәлеп килгән кануннарына буйсынып, телебезне, динебезне, милли йөзебезне үзебезгә хас югарылыкта торгарга мөмкинлек бирер дигән өметтә калабыз.

Яшәү һәм үлем... Беренче карашка ук капма-каршы тоелган бу ике төшенчә татар кешесе аңында бер-берсеннән аерылгысыз кабул ителә. Үлем – кеше тормышының тәгәлләнүе, өзелүе.

Татарларның исламга кадәр формалашкан мифологик аңында җир йөзен үрдәк яраткан, ул диңгез төбенә чумып җир алган, шуннан дөнья яралган дигән күзаллау яши. Кешенең үлемен дә үрдәк үлеме белән тәңгәлләштереп карау бүген дә әдәбиятта яшәп килә. Кеше туганда, аның өчен дөнья ярала, ул үлгәндә, дөнья да юкка чыга. Якын кешенең үлеме – исәннәр өчен кайгы-хәсрәт. Әмма татарлар нәселнең дәвам итүен дөньядан үткәннәр өчен мөһим дип саный. Якынын югалткан татар гаиләсендә исә «әрвах» төшенчәсе аркылы аңа үзенчәлекле, хәтта беркадәр ихтирамлы караш булдырыла. Инде бакыйлыкка күчкән буыннарга – әрвахларга таяну һәм ата-баба рухының нәсел-нәсәпне ярдәмсез, терәксез калдырмавына инану бик борынгыдан сакланып калган. Татар гаиләсе нинди генә зур эшкә тотынмасын – нәсел дәвамчысы улы яки оныгы туамы, кызын кияүгә бирәме, улын өйләндерәме, олы, җаваплы сәфәргә җыенамы, солдатка алынамы – ярдәм-киңәшенә, фатихасына өметләнеп, һәрвакыт нәсел-нәсәп әрвахларына мөрәҗәгать итә. Һәр нәселнең язылмаган, әмма үзләре өчен кабул ителгән яшәү рәвеше була – аның дәвамчылары, нәселнең йөз аклыгын, намусын сакларга теләү белән бергә, әрвахларны ризалатыр өчен дә, шул кануннарны төгәл үтәп яшәргә тырыша. Татарларның үлемгә мөнәсәбәте менә шушы күзаллаулар нәтиҗәсендә формалашкан.

Яшисен яшәп, ашыйсын ашап, эчәсен эчеп фани дөньядан бакыйлыкка күчү – аның өчен табигый күренеш. Озын һәм матур гомер кичергән, нәселнең йөз күрке булып яшәгәннәрнең җаны бакыйлыкта әрвах затына әверелә дип күзаллау үлемне билгеле бер югарылыкка, хәтта дәрәҗәгә күтәрә. Адәм баласының кайберсе бик иртә, әле яши генә башлаган мәлендә фани дөньяны ташлап китә. Бу хәл – яшьли бакыйлыкка күчү – татар акылында фаҗига буларак кабул ителә. Шулай да гомер буе сабырлыкка омтылган халык бу юлы да үз холкына тугрылыклы: «Җыяр ризыклары беткәндер, гомере шулай кыска язылгандыр инде» кебек сүзләр белән юанырга тырыша ул.

Икенче берәүләр балалар, оныклар үстереп, аларның тәрбиясенә тиенеп, озак һәм матур яшәп дөньядан үтә. Халык, андыйларга карап: «Бәхетле гомер кичерде, бар бурычын үтәп бетерде, тыныч үлем насыйп булды», – дип соклана.

Итәк тутырып үскән оныкларны күрү, аларны кулга алып сөю бәхетенә ирешү – татар кешесенең горурлыгы да, яшәү мәгънәсе дә. Димәк, гомер заяга үтмәгән!

Үзеңнән соң да тормыш дәвам итәчәк, нәсел чылбыры өзелмәячәк... Күрәсең, нәкъ менә шуңа күрә татар хатыннары, беренче онык дөньяга килүгә, үзләре өчен үлемтек әзерләүгә керешә дә инде. Кыз бала тугач, йөгерә-йөгерә бирнә җыю, аның туена әзерләну иң җаваплы гамәлләрнең берсе саналса, онык тугач, үлемтек хәстәрли башлау гомернең өченче туена, соңгысына әзерләну буларак аңлашыла. Хатын үлемтекне үзенә дә, иренә дә бертигез итеп хәстәрли. Үлемтек әйберләре, гадәттә, гомер дәвамында шактый бушап калган бирнә сандыгына тутырыла. Анда салынырга тиешле һәр кирәк-ярак элек-электән килгән тәртипләргә нигезләнеп әзерләнә. Бер генә әйбер дә күз уңыннан читтә калмый: мәетне юу өчен су китерүчеләргә, кәфен кисүчеләргә һәм тегүчеләргә, мәет юучыларга, гүргә иңдерүчеләргә, төн саклауда катнашучыларга, кабер казучыларга һәм башкаларга өләшенергә тиешле кирәк-яраклар белән исле сабыннар, ислемайлар да салына, кәфенлек өчен тиешле күләмдә ак бәз тукыма, энә-җепләр дә әзерләнә. Үлемтек әйберләре бик якыннарга гына күрсәтелә, андагы тәртипне төп йортта яшәүче килене яисә олы кыз гына белә.

Гомер буе ахирәтләр булып аралашкан хатын-кызлар да үлемтек әйберләрен бер-берсенә күрсәтеп киңәшләшергә мөмкин, бу да

гадәти хәл. Татарлар арасында «үлемтек әйберләрен никадәр алдан хәстәрләсәң, алар сиңа шулкадәр гомер теләп торыр» дигән ышану да яшәп килә. Ничек кенә булмасын, бу мәгънәле гамәлнең асылында үлемне зурлап көтеп алу ята. Игътибар итсәгез, халык телендә җанлы кулланылышта йөргән мәкаль-әйтемнәр дә үлемнең табигый халәт булуын аңлата.

Атам – Мәккә, анам – Мәккә,
Туылганмын мин үлмәккә,
Аталардан мирас калган
Кара җиргә күмелмәккә.

Үлем кешегә төрле вакытта килергә мөмкин. Кайчан һәм ничек кенә булмасын, татар кешесе, күзе ачык, акылы бар чакта, янындагыларга үз гозерен җиткерергә ашыга: җан биргәндә янәшәсендә кемнәрне күрергә, җаны чыгар алдыннан ясинны кемнән укытырга теләвен дә ирештерә. Якыннары исә үлем түшәгендә ятучының бар гозерен мөмкин кадәр тизрәк үтәргә тырыша. Алар өчен бу да бик мөһим, чөнки адәм баласының җаны бакыйлыкка тынычлык белән, хәер-фатиха калдырып күчәргә тиешлеген барысы да яхшы аңлый. Үлем белән яшәү арасы бер бөртек чәч калынлыгы гына исәпләнгән мизгелләрдә, үлем түшәгендә ятучы якыннарын бәхилләргә тырыша. Аның бәхилләшә алуы җанына/рухына җиңеллек бирә дип аңлашылса, бәхиллек алып калу исәннәр өчен бик зур савап санала. Әгәр бакыйлыкка күчүче ясин укучының кем булырга тиешлеген алдан тәгаенләмәгән булса, бу очракта аның янына мулла чакырыла, мулла килә алмаса, догалар укый белүче башка берәүне дәшәләр. Мулла, үлем түшәгендә ятучы янына килгәч, кычкырып ясин укырга тотына: бу гамәл үлем газабын һәм кабер газапларын җиңеләйтү өчен башкарыла. Үлем түшәгендә ятучы, хәленнән килгәнчә, якыннары белән бергә: «Ләә иләәһә илләллаһү», – дип кабатларга тырыша. Бу – мәетнең җаны теге дөньяда тизрәк үз урынын тапсын дип эшләнә. Җанның тәннән аерылу мизгелләре адәм баласы кичерергә тиешле иң газаплы мизгелләрнең берсе буларак кабул ителә.

Татар халкы аны тикмәгә генә «үлем – әҗәл ачысы» димәгән, әлеге мизгелләрне кичү халәтен аңлату максатыннан мөнәҗәтләр иҗат итмәгән!

Күкрәгем кыса, тыннарым бетә,
Ясин укырга вакытлар җитә.
Җаным чыкканда, янда булыгыз,
«Шаһәдәт берлән күч» дип торыгыз! –

кебек юлларда үлем түшәгендәге кешенең якыннарына соңгы гозере чагыла.

Үлем газабы соңгы сулышын алып ятучыга да, аның якыннарына да бик авыр, аны кичергән кеше үзе генә белә, үзе генә аңлый.

Татар халкы күзаллавынча, үлем бервакытта да кинәт, кисәтүсез килми, аның хакындагы хәбәр нинди дә булса билге ярдәмендә алдан ук ирештерелә. Мәсәлән, төштә кара яисә күк ат күрүне мәеткә юрыйлар; татарларның мифологик күзаллауларында бу образ җан алырга килүче Газраил образы белән тәңгәлләштерелә. Моннан тыш, төштә теге яисә бу йорт каршында бура күтәрү дә үлем хәбәре буларак кабул ителә. Борынгы төрки-татарларның мәет җирләү йолаларында кабер өстенә бура күтәреп кую гадәте булган, бураның үлем хәбәрчесе саналуын шуның белән бәйләп аңлатырга мөмкин. Төштә йортның матчасы яисә миче җимерелгәнне күрсәң, йорт хуҗасының, ата-ананың үлеменә ишарә дип аңлау да яшәп килә. Йорт өстеннән козгын, кара карга кычкырып үтүен, ишегалдындагы этнең туктаусыз улавын да мәет хәбәре дип кабул итү бар. Шуңа күрә «хәбәр»не ничек тә уңайга борырга теләп, «үз башыңа кычкырсаң иде», «үз башыңа уласаң иде» диләр. Татарларның үлемгә бәйле башка күзәтүләре дә бар, мәсәлән: «Мәрхүм буласы кешенең, үлеменә 40 көн кала, күзләреннән нуры кача, рухы сүлпәнләнә, җилкәләре иңә». Болар барысы да үлемнең беркемне дә аямый торган табигый хәл икәнлеген аңларга җирлек бирә.

# Милли хәзинәләр – буыннарга мирас

**Ләйлә Мөхәмммәтгалиева,**
*«Әллүки» балалар фольклор төркеме җитәкчесе*



**Арча районы Мәдәният йорты каршында оешкан «Әллүки» балалар фольклор коллективы үзенең иҗади эшчәнлеген быелның февраль аенда башлап җибәрде**

«Әллүки»ләр беренче көннәреннән үк район һәм республикакүләм чараларда актив катнаша, төрле конкурсларда, фестивальләрдә уңышлар яулый. Мәсәлән, Мари Эл республикасында үткәрелгән «Чулпан» I Бөтенроссия балалар иҗаты конкурсының фольклор номинациясендә 1нче дәрәҗә лауреат Дипломына лаек булдылар. Казан мэриясенең «Древо жизни» – «Байтирәк» мәгърифәти проектында, Кайбыч районындагы – «Кичке уен», Әтнә районы Кышлау авылында узган «Җиз самавыр» фольклор фестивальләрендә чыгыш ясадылар.










2025
ГОД ЗАЩИТНИКА
ОТЕЧЕСТВА
РАЙОННЫЙ КОНКУРС
«ЗАЩИТНИК ОТЕЧЕСТВА -
ГОРДОЕ ЗВАНИЕ!»



Төркемнең репертуары, нигездә, «Ат тоягы кыздыру», «Уракчы кызлар», «Нәүрүз», «Каз өмәсе» кебек фольклор-этнографик күренешләрдән тора. Коллектив театр сәнгате белән дә таныша: Ватанны саклаучылар елы уңаеннан, Туфан Миңнуллинның «Иптәш командир» пьесасына нигезләнеп, спектакль әзерлиләр.

Бүгенге көндә коллективта 6-10 яшьлек (5 малай һәм 15 кыз) 20 бала шөгыльләнә. Биредә баянчы егет тә бар. Төркем татар фольклорын, халык киемнәрен, милли уеннарны, җыр-такмакларны таныту максатыннан тупланды. Балалар биредә бары тик татар телендә аралаша, һәм алар үзләренең Арча ягына гына хас гореф-гадәтләрне, йолаларны өйрәнәләр. Шунысы куандыра: фольклор күренешләр аша балалар әби-бабаларның, татар халкының көнкүреше белән таныша ала.

Милли хәзинәләребез югалмасын, күп көч, тырышлык белән җыелган архив материаллары, буыннан-буынга күчеп, мирас булып саклансын иде. Максатыбыз: алга таба үсү, олы үрләр яулау.

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**



# Алтын алмалар

## (Татар халык әкиятенә нигезләнеп сәхнәләштерү)

**Гөлфинур Зәйнакова,**
**Рәмзия Гарифуллина,**
**Алсу Гаффарова**
*Арча, 10нчы балалар бакчасы тәрбиячеләре*

**Катнашалар:**

**Бай, бай хатыны, ярлы кеше, ярлының хатыны, ярлының җиде баласы, алып баручы**

**Алып баручы:**

Борын-борын заманда
Чалпы дигән авылда
Яшәгән ди бер бай.
Исеме Вәли булган ди,
Эчендә булган ди биш пот май.

Туктагыз әле, ник сөйләп торам соң әле сезгә, үз күзегез белән күрегез. Әкиятне башлыйбыз!

*(Бай өе. Бай һәм аның хатыны өстәл артында чәй эчәләр.)*

**Бай:** Күр әле, Мәрьямҗамал, безнең уң як күршеләр бигрәк күңелле яшиләр. Синә да шулай тоеламы ул?

*(Сәхнә артында көлгән тавышлар ишетелә.)*

**Бай хатыны:** Әй, кем караган да, кем тикшергән аларны. Тапкансың исең китәр әйбер!

**Бай:** Тукта әле, тукта, алай димә. Безнең өйдә күңелсез, ә аларда гел көлешәләр... Әнә, әнә күрше урамга чыккан. Тукта, син монда кал, чыгып сорыйм әле мин аннан. *(Урамга чыга.)*

**Бай:** Әссәләмәгаләйкүм, күрше!

**Ярлы:** Вәгаләйкүмәссәлам, Вәли бай! Ни хәлләрең бар?

**Бай:** Кара әле, күрше, кайчаннан бирле сезне күзәтеп йөрим, мин әйтәм бигрәк шат яшисез сез. Юкса ашарыгызга да җитми торгандыр, тамагыгыз да туймыйдыр. Киемнәрегез дә безнеке сыман затлы түгел, ә күңелегез гел күтәренке. Менә безнең акчабыз да, малыбыз да күп, тик өйдә никтер күңелсез. Бу ник алай икән?

**Ярлы:** Хәй, Вәли бай, аның сере бик гади. Безнең өйдә җиде алтын алмабыз бар. Әй, яратабыз шуларны, бәхет китерүчеләребезне. Без кичләрен шулар белән уйныйбыз. Алар белән һәр көнебез күңелле.

**Бай:** Әәә, имәндә икән чикләвек! Аннан гына торса, минем дә акчам күп, мин дә хәзер үк базардан алтын алмалар сатып алам. *(Китә.)*

*(Базар күренеше.)*

**Сатучы:** Алма сатам! Кемгә алма кирәк? Алтын алмалар, йомры алмалар, ут кебек янып торалар.

**Бай:** Кая, китер әле, мин алам. Миңа җиде алтын алма бир.

*(Өенә кайта.)*

**Бай:** Менә, хатын, кара әле. Мин җиде алтын алма сатып алдым. Хәзер бәхет, күңелле тормыш бездә булачак. Әй, кызык, рәхәт булачак!

**Бай хатыны:** Күрсәт әле, кая. Ай-яй, бигрәк матурлар, янып торалар!

**Бай:** Әйдә, уйнап карыйк әле. Утыр, карчык, өйнең әнә теге почмагына.

*(Икесе ике почмакка утырып, бер-берсенә алма тәгәрәтәләр.)*

**Бай хатыны:** Уф, Вәли, арыдым мин. Бер дә кызыгын тапмыйм, күңелле урыны кайчан башланыр икән?!

**Бай:** Әйе шул, сәер хәл, туйдырды бу уен. Алдаган ахыры мине күрше. Әйдә, карчык, күршеләргә кереп, аларның алтын алмаларын карап чыгыйк әле. Алдаган булсалар, миннән рәхим-шәфкать көтмәсеннәр!

*(Күршеләргә кереп китәләр.)*

**Бергә:** Әссәләмәгаләйкүм!

**Ярлы:** Вәгаләйкүмәссәлам! Аллага шөкер, күршеләр, әйдәгез, рәхим итегез.

**Ярлы хатыны:** Әйдә, әйдә түрдән узыгыз, утырыгыз. Хәзер чәй әзерлим.

**Бай хатыны:** Менә сезнең балаларыгызга бераз ризык алып кердек!

**Ярлы хатыны:** Әй, рәхмәт яусын! Өстәлебез мул булмаса да, барына да җитешегез. Менә үз кулчтәнәчләрегездән авыз итегез, озын гомерле булырсыз. *(Чәй эчәләр.)*

**Бай:** Я, күрше, син бая алтын алмаларыңны мактаган идең, күрсәт инде безгә шуларны.

**Ярлы:** Була ул, хәзер, бай абзый. Әнисе, бар, чакыр әле балаларны.

**Ярлы хатыны:** Балалар, килегез әле монда. *(Җиде бала йөгереп чыга.)* Күрәсезме, безгә күршеләр, Вәли бай белән Мәрьямҗамал апагыз керде. Әйдә, һөнәрләрегезне күрсәтегез әле!

**Беренче бала:** Әти, без җырлап күрсәтәбез.

*(«Биилэр итек, читекләр» җыры башкарыла.)*

Гармун уйныйм, гармун уйныйм,
Һаман гармун уйныйм мин.
Остарып җиткәч, барсын да
Биетергә уйлыйм мин.

Учларыңны шакылдатып,
Чәчләреңне сыпыр да.
Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр,
Тыпыр-тыпыр тыпырда.

Әй, бии итек, читекләр!
Әй, уйныйм мин, уйныйм мин.
Минем кебек шәп гармунчы
Юктыр диеп уйлыйм мин!

**Ярлы:** Улым, синең нинди һөнәрең бар?

**Икенче бала:** Ә мин әкият сөйли беләм. Борын-борын заманда яшәгән ди әби белән бабай. Аларның өйләре булган ди таштан, сөйлимме яңа баштан?

**Балалар:** Сөйлә, абый, сөйлә!

*(Бала шуны ук кабатлый, көлешәләр.)*



**Ярлы хатыны:** Әй, улым, алдый торган әкият булды бит бу.

**Ярлы:** Кызларым, бай абзыйга биеп күрсәтмисезме соң!?

*(Татар халык биюе башкарыла.)*

**Өченче бала:** Без татар халык мәкальләрен беләбез.

**Дүртенче бала:** Агач җимеше белән, кеше эше белән матур.

**Бишенче бала:** Тырышкан табар, ташка кадак кагар.

**Алтынчы бала:** Аз сөйлә, күп эшлә.

**Җиденче бала:** Ни чәчсәң, шуны урырсың.

**Ярлы:** Рәхмәт, балалар, булдырдыгыз! Менә бай абзый, шушылар инде безнең алтын алмаларыбыз.

**Бай:** Әйе, күрше, менә хәзер аңладым инде. Балалар белән күңелле икән тормышыгыз. Мондый алтын алмалар миндә юк шул. Болай булгач, сезнең байлык минекеннән күбрәк була түгелме?!

**Ярлы хатыны:** Әйе, балалар – безнең бәхетебез! Аларның уңышлары безне сөендерә, киләчәккә өмет уята.

**Бай хатыны:** Күршеләр, әйдәгез, безнең гаиләләр һәрвакыт дус булып яшәсеннәр әле! Бергә-бергә күңелле икән бит!

**Беренче бала:**
Тарт син, эти, әйдә, бас төймәңә,
Чыксын синең, моңлы көйләрең.
Уйна гармун, тарат моңнарыңны,
Безнең татар халык көйләрен.

*(«Суда йөзә аласыңмы» көенә күмәк җыр башкарыла.)*

Әй, дусларым, сезгә әйтәм:
Әткәй – шикәр, әнкәй – бал!
Гаиләң булу – бәхет бит ул!
Өең тулы – балалар!

*Кушымта:*
Суда-суда,
Суда йөзә аласыңмы?
Безнең кебек тату гаилә
Эзләп таба аласыңмы?

Бәхетле гаиләнең сере –
Бердәмлектә бит, дуслар!
Шундый гаиләләр булганда,
Илнең киләчәге бар!

*Кушымта:* шул ук.

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**

# Чыланган чыршылар

*Наилә Яхина көе,*
*Йолдыз сүзләре*




*Яңа ел бәйрәме җитә,*
*Тик никтер яңгыр ява.*
*Көзге моңсу көн шикелле*
*Тымызык дымсу һава.*

***Кушымта:***
*Яңа ел һич килми калмас,*
*Тиздән ишек ул шакыр.*
*Аңарчы каян табарга*
*Чыршыларга кулчатыр?!*
*Койма яңгыр, шыбыр-шыбыр!*
*Яума яңгыр, туктап тор!*

*Чыршылар бәйрәм җитә дип,*
*Яшел күлмәк кигәннәр.*
*Итәкләре чыланганга,*
*Күр, башларын игәннәр.*

***Кушымта: шул ук.***

*Ишетәм лә чыр-чуларын,*
*Аңламыйм борчуларын.*
*Күлмәкләре чыланганга*
*Чирканган чыршыларның.*

***Кушымта: шул ук.***

**Журнал укучыларыбызны бүген, Балтач районы Бөрбаш авылы халкында элек-электән сакланып килгән камыр ризыгы уалма белән, Гүзәл Миңнемуллина таныштыра. Гүзәл Бөрбаш Мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе булып эшли.**



# УАЛМА

– Уалманы «каты күмәч» дип тә атыйлар. Кетер-кетер килеп, уалып торганга «уалма» дип атаганнар. Аны Кукмара якларында борчак оныннан да пешерәләр. Мин Бөрбашка 10 ел элек килен булып төштем. Каенатамның әнисе Гөлчәчәк әбигә хәзер 89 яшь. Балачагын искә төшергәндә шушы уалманы (каты күмәч) ничек пешерүләре турында еш сөйли. «Без юклыкта үстек. Уалма пешкән көнне без – бала-чагага бәйрәм була иде. Хәзерге печенье, прәннекләрне алыштыра торган, иң тәмле ризык санала иде», – ди ул.

**КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР:**

*0,5 бал кашыгы тоз,*
*1 аш кашыгы шикәр комы,*
*0,5 стакан җылы сөт,*
*0,5 стаканнан артыграк сыек май,*
*0,5 бал кашыгы камыр көпшәкләндергеч (чәй содасы),*
*2 данә йомырка,*
*кирәгенчә он.*



1 *Уалма өчен кирәкле булган ингредиентларны барысын да алдан әзерләп куябыз. Бармак пешмәслек итеп, сөтне җылытабыз.*



2 *Кирәкле булган ингредиентларны кушып, катырак итеп камыр басабыз.*



3 *Камырны батон формасында әвәләп, 1,5 сантиметр калынлыкта телемнәргә кисәбез.*



4 *Шул телемнәрне алдан әзерләп куелган майлы табага тезәбез. Өстенә бармаклар белән баскалап куябыз.*



5 *Уалма тезелгән табаны 180 градуслы кызган мичкә тыгып, 20-25 минут пешерәбез.*



6 *Пешеп чыккан уалманы чәй, сөт белән ашарга мөмкин.*
***Ашларыгыз тәмле булсын!***

**Фоторәсемнәр Гүзәл Миңнемуллинаның шәхси архивыннан**

# Бергәләп бизибез!



# Истәлекле даталар
# 2026

## ГЫЙНВАР

**1 гыйнвар**

Татар әдәбиятының классик шагыйре Һади Такташның (Мөхәммәтһади Хәйрулла улы Такташев) тууына 125 ел (1901-1931)

**4 гыйнвар**

Рәссам, график, педагог Мәгъшия Мөбарәк кызы Мөхәммәтовага 75 яшь (1951)

**4 гыйнвар**

Рәссам, монументаль сәнгать остасы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Шамил Габдрахман улы Нигъмәтуллинның тууына 75 ел (1951-2004)

**6 гыйнвар**

Баянчы, композитор, аккордеончы, ТАССРның халык артисты Рәшит Шәкүр улы Мостафинның тууына 80 ел (1946-2023)

**6 гыйнвар**

Актёр, Татарстан Республикасының халык артисты Габделфәрт Әхәт улы Шәрәфиевнең тууына 75 ел (1951-2014)

**10 гыйнвар**

Дирижёр, СССРның, Украина ССРның һәм ТАССРның халык артисты, СССРның Дәүләт премиясе лауреаты Натан Григорьевич Рахлинның тууына 120 ел (1906-1979)

**10 гыйнвар**

Җырчы, Татарстан Республикасының халык артисты Резеда Дамир кызы Шәрәфиеваның тууына 60 ел (1966-2025)

**15 гыйнвар**

Сынчы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Кадим Җәлил улы Җәмитовка 80 яшь (1946)

**16 гыйнвар**

Рәссам, график Рәшит Хәмит улы Гаимовка 75 яшь (1951)

**25 гыйнвар**

Рәссам, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Шамил Камил улы Якуповка 70 яшь (1956)

**29 гыйнвар**

Архитектор, рәссам, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык рәссамы, Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ильяс Сәйяр улы Айдаровка 70 яшь (1956)

## ФЕВРАЛЬ

**3 февраль**

Балет артисткасы, балетмейстер, профессор, РСФСРның һәм Татарстан Республикасының халык артисткасы Нинель Даут кызы Юлтыеваның тууына 100 ел (1926-2014)

**8 февраль**

Актриса, педагог, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисткасы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Шаһсәнәм Ибраһимбәк кызы Әсфәндиярованың тууына 100 ел (1926-1996)

**9 февраль**

Гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы Татьяна Владиславовна Соловьевага 60 яшь (1966)

**10 февраль**

Җырчы, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Вафирә Мөхәммәтдин кызы Гыйззәтуллинаның тууына 80 ел (1946-2001)

**14 февраль**

Гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәшид Садри улы Шиһабетдиновка 80 яшь (1946)

**27 февраль**

Режиссёр, театр белгече, педагог, сәнгать фәннәре кандидаты, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Халит Лотфулла улы Кумысниковның тууына 100 ел (1926-2008)

## МАРТ

**13 март**

Гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, сәнгать белеме кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Лариса Николаевна Донинага 60 яшь (1966)

**16 март**

Гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы Юлия Эдмондовна Болдырёвага 60 яшь (1966)

**19 март**

Балет артисты, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Камил Гайфулла улы Гайнуллинга 80 яшь (1946)

**29 март**

Балет артисты, ТАССРның, РСФСРның халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ирина Шәриф кызы Хәкимовага 75 яшь (1951)

**https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды**







**Кадерле укучыларыбыз!**
2026 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 294 сум 07 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 588 сум 14 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!